
Тәүфикъ Әйди
ЯНА УЕН

Тәүфикъ Әйди

ЯҢА УЕН

ХИКӘЯЛӘР

ҚАЗАН
ТАТАРСТАН ҚИТАП НӘШРИЯТЫ
1988

ББК 84(2Р-Тат)-4
Ә30

Әйделдинев Т. Р.

Ә30 Яңа уен: Хикәяләр.— Казан: Татар. кит. нәшр., 1988.—112 бит.

Уеннарның төрлесе була. Яңгырдан соң, гөрләвекләр белән узышып, ялан тәпи йөгерә аласың яки тау битендә, үзеңне тегермән эчендә хис кылып, туфрактан теттереп «он» тарттырасың. Ләкин, чынлап торып уйласаң, бик файдалы уеннар уйнарга да мөмкин икән бит. Әйтик, нигә әле туган авылыңның йортларын, бакчаларын, хуҗалык һәм культура үзәкләрен чагылдырып, үзле балчыктан аның макетын коеп куймаска? Бу китаптагы геройлар чынлап та шундый эшкә керешәләр. Монда күңелле, хәтта күңелсез хәлләр дә була, аларны, кызыгын югалтып, сезгә әйтеп тормыйк инде. Бары колагыгызга шуны гына әйтәбез: бу китаптагы хикәяләрдән сез дуслык һәм гаделлекнең чын асылын, авыр чакта иптәшеңә ярдәм итүнең нинди күркәм, әйбәт сыйфат икәнлеген белә алырсыз.

Ә $\frac{4803010200-325}{М132(03)-88}$ 176—88 ББК 84(2Р-Тат)-4

© Татарстан китап нәшрияты, 1988.

ДАЧАДА

Айнур белән Алсу шәһәр уртасында яши. Биек ташпулатның сигезенче катында. Әти-әниләре эшкә киткәч кенә уяналар да ашыкмыйча гына юыналар. Абыйсы битен сабынлагач кына, Алсу кранга барып ябыша. Кайнар суны я бик әз, я чамасыз күп җибәрә, үзе чырык-чырык көлә. Айнур, бик ачуы чыкса да, сеңлесенә каты бәрелми: нәрсә белә ул? Дүрт кенә яшь ич әле аңа, абыйсыннан нәкъ бер яшькә нәнирәк «бөтерчек».

Ләкин дәү әниләре аларга су белән артык булашырга ирек бирми. Ботка суына, дип ашыктыра.

Залга келәм түшәлгән, шунда тәгәрәшеп уйнарга уенчыклары да дөнья кадәр. Телевизордан рәхәтләнеп мультфильмнар карасаң да була. Анысы туйдырса, балконга чыгып, туйганчы урам күзәтәсең.

Анда тыз-быз машиналар чаба, трамвайлар йөгерә. Абыйлар, апалар, әбиләр, бабайлар каядыр ашыга, тирә-юньдәге йортлар артына — балконнан да күренми торган әллә кайларга китеп югалалар.

Әнә шунда Айнур белән Алсуның да барасы килә. Әмма урамга чыккач та, дәүәниләре аларны ишегалдыннан ары җибәрми. Таган атынырга, комда казынырга, күршеләре белән куыш уйнарга гына ирек бирә дә, Айнур белән Алсу кызып җиткәндә генә, аларны өйгә алып кереп китә. Авыз турсайтып икәүләшеп елашсалар да, җинә алмыйлар үзен!

Ә быелгы яз аларга көтелмәгән шатлык алып килде. Әтиләре шәһәр кырыенда дача алды. Карлар эреп бетүгә, ул ял көннәрен еш кына шунда китеп югала башлады. Айнур белән Алсу аңар:

— Мине дә алып бар инде?

— Мине дә! — дип ялынырга тотындылар.

Тик әтиләре аларны ияртергә бер дә ашыкмады.

— Кызым, анда хәстәрен күрәсе — куаклар утыртасы бар әле.

— Дача өен дә корып бетермәгән әле, улым. Яңгыр ява башласа, җил-давыл чыкса, нишләрбез? Аннары, утырып ашарга өстәл, урындыклар да юк әле анда!

— Ә без аны карап кына кайтабыз, — диде Алсу.

— Я, өлгерерсез әле, борчымагыз әтиегезне, — дип туктатты аларны әниләре. — Көннәр җылынсын, гөлләр чәчәк атсын. Һич югы, җиләк пешсен. Ул арада әтиегез дә өйне салып бетерер.

— Әни, анда урман да бармыни? — дип сорады Алсу.

— Бар. Дачабыз нәкъ каенлык кочагында гына.

— Ә ул моннан еракмы? — диде Айнур.

— Ерак. Башта трамвайда, аннары автобуста барасы.

— Ә ул урманда куян бармы?

— Ә бүре? — дип кушылды сеңелесенә Айнур.

Әниләре аларның икесенә берьюлы җавап бирде:

— Җиек-җәнлек шунда яши инде. Куяны да, бүресе дә җитәрлек. Кырмыскалар, керпеләр, сыерчыклар, күкеләр — нәрсә генә юк анда.

— Күке нинди була соң ул?

— Ә мәче, маэмайлар бармы?

— Куян белән бүре дачага да киләләрме?

— Мин анда мылтык алып барам, — диде Айнур.

— Ә мин алардан болай да курыкмыйм, — диде Алсу. — Сыбызгы сызгыртам да куып җибәрәм. Милиционер килә, дип белеп үзләре үк сыпыртачак!

— Юләр! — дип көлде Айнур. — Урманда милиционер буламыни? Куян болай да кешегә тими ул, тик кунакка килеп йөрсен.

— Ә мин бүрене яратам, — диде Алсу, абыйсына киреләнеп. — Мин кунакка да шуны гына чакырачакмын.

Үзсүзле Алсуның кашлары җыерылган, саргылт чәчләре маңгаена төшкән, почык борыны түшәмгә караган. Сеңлесенең кылтаюына исе китмәгән төсле егетләнеп маташкан Айнур сипкелле йөзенә мыскыллы елмаю чыгарган. Әниләре аларга көлемсерәп карап торды да, икесенең дә иңнәреннән кагып, залга чыгарып җибәрде.

— Аяк астында чуалмагыз әле, аш пешерәсем бар.

Кызганыч. Айнур белән Алсуның сорыйсы нәрсәләре әле муеннан иде. Шундый чакта дәүәниләре дә өйдә юк ичмаса, әллә кайда кунакта йөри. Икәү генә баш ват инде менә хәзер. Әтиләре кайчан ко-рып бетерер икән инде ул дача өен? Хәзер үк алып барса, ни буладыр, бергә-бергә эшен дә ялт тәмамларлар иде. Алсу әтисенә салат ясап ашатыр, ә Айнур такталарын кадаклашыр иде. Көне буе уйнап та армыйлар ич әле. Әтисе белән әнисе эштән кайтуга, аларның башмакларын Айнур белән Алсу табып кидерә, телевизорны да алар кабыза, Яңа ел бәйрәменә ала торган әфлисуннарны да Айнур белән Алсу әрчеп бирә, ләбаса. Пычаксыз-нисез, бармак белән генә каезлыйлар! Алсу әфлисунны абыйсыннан да остарак телемнәргә телә, шунлыктан аңа «абый» дияргә дә атлыкмый. Караңгыда да курыкмый әле ул, бик беләсегез килсә. Кухняга төнлә ялгызы кереп чәй дә эчә.

Кояшлы июнь уртасында, ниһаять, түземсезләнеп көткән сәфәргә җыена башладылар. Айнур белән Алсу киемнәрен, уенчыкларын кичтән үк барлап куйдылар. Әллә ничә көнгә баргач, мәчеләрен дә үзләре белән алырга булдылар. Еракта, зәңгәр офык артындагы серле урман буенда бергәләп уйнарга.

Ул көнне абый белән сеңел йокыдан ялындырмыйча иртүк уянды. Ашыйсылары килмәсә дә, куйган ризыкны олыларга карышмый гына ялтыраттылар. Бик тә ерак юл көтә ич аларны!

Юлда Айнур белән Алсуның авызлары гел

ерылып кына торды. Әллә инде эти-әнисенә ярарга тырышып, әллә ялгышып шунда, Алсу Айнурга берничә тапкыр хәтта «Абый!» дип тә эндәшеп куйды. Моңа күңеле эрегән Айнур мәче утыртылган әрҗәне сеңлесе кулыннан алып, үзе тотып барырга булды. Ә инде аларның икәүләшеп сорау арты сорау яудырулары юл буена җитте.

Сәяхәтчеләр автобустан шәмдәй төз чыршы-наратлар үсеп утырган бер борылышта төшеп калды. Алар белән бергә автобустан коелган юлдашлары бик тиз урман сукмаклары буйлап кереп китте дә, комга сибелгән судай, югалды. Айнур белән Алсу исә, як-якка таң калып карый-карый, әтиләре артыннан иярде. Менә кайда кызык икән ул — шау чәчәккә төренгән аланнарда Айнур белән Алсу әле беркайчан да күрмәгән, ишетмәгән чикерткәләр чырылдый, аклы-күкле күбәләкләр оча, кошлар сайрый. Баш очында табак кадәр кояш кыздыра, һавасы шундый тәмле — сулаган саен сулыйсы гына килә. Бераздан якты каенлыкка килеп чыктылар. Арба, җиңел машина эзләре беленеп торган ямьяшел йомшак юл аларны яңа койма буеннан биек капкага алып килде. Янәшәдәге каравылчы өе алдында бәйгә куелган бияләйдәй җәлпәк борынлы, уклау сыйраклы, шома йонлы эт аларга усал гына ырылдап калды, аның янында бөтерелгән ала-кола нәни йөнтәс маэмай исә, койрыгын болгый-болгый, яңа килүчеләргә сырпаланды. Айнур аңа кесәсендә аунап йөреп карала башлаган шикәр шакмагын каптырып:

— Муйнакмы син? — дип эндәште.

Алсу исә, абыйсының көчекне әнә шулай бик тиз ияләштерүенә көнләшеп:

— Ул Муйнак түгел, Акмуен! — диде.

Шуннан соң әниләре:

— Ягез, теләсә нинди алабайга барып ябышмагыз әле! — дип, аларның икесен дә үзеннән алгарак уздырып җибәрде.

Дачалары каенлык уртасындагы аланда икән. Әкияттәге төсле нәни өй зәңгәр, яшел, ак буяуларга буялган. Тик ул тыштан караганда гына шулай кечкенә тоела, эче хәйран иркен икән. Озынча бүлмәгә өстәл-урындыклар да, кием шкафы белән буфет та сыйган. Якты верандасының аргы башында — газ плитәсе, бирге ягында — эш кораллары, буяу савытлары. Тегендә-монда таралып яткан әйберләрне күреп, Айнур белән Алсу куанып кына куйдылар — берәү дә: «Өйне тузгытасыз!» — дип аларның теңкәсенә тимәс.

Тагын шунысы кызык иде: бөтен җирдә яңа юнылган агач, чәер һәм буяу исе аңкый. Тактадан гына салынган стеналар юп-юка, веранданың бер ягы исә тоташ тәрәзә генә. Бернинди буяу тимәгән идәне гәрәбәдәй сап-сары. Алар Алсу сикергәләп карагач та сыгылмады, күңелле дөбердәп кенә куйдылар.

— Я, ничек, ошыймы сезгә дача? — дип сорады алардан әтиләре.

— Әй-йе. Без монда хәзер җәй буе торачакбызмы?

— Теләсәгез, җәй буе да мөмкин.

Әниләре, килеп җитүгә, аш-су әзерли башлады. Әбиләре яшелчәләргә су сибәргә чыгып китте. Әти-

ләре исә Айнур белән Алсуны кызыксындырган култыксалы баскычка юнәлде. Менә гаҗәп! Бераз күтәрелгәч, ул ике кулы белән баш очындагы такталарны эткән иде, түшәм ишек кебек өскә ачылды да китте. Ур-ра! Монда берсендә диван, икенчесендә караватлар тезелешеп торган бүлмәләр бар икән ич. Айнур керү уңаенда ук шуларда мәтәлчек атынып алды, ә Алсу аларның берсе янына ашыгып:

— Бусы — миңа! — дип кычкырды.

Тиздән аш өлгерде, чәй кайнады. Яңа дача өендә беренче мәртәбә түгәрәк табын янына җыелдылар. Шатлыкны кайбер күршеләр дә уртаклашты. Алар Айнур белән Алсуга үзләре шушында үстергән чәчәк бәйләмнәре бүләк иттеләр.

Әй кызык икән дачада. Тәрәзә-ишекләр ачык, бүлмәгә безелдәп бал кортлары, төклетуралар очып керә. Шулпаны монда җамаяктан гына ашыйсың, балга аш кашыгы белән сузыласың! Әти-әниләре күпме ташыса да, дачада һаман савыт-саба җитми икән әле.

Тамак туйгач ук, Айнур белән Алсу тышка чыгып киттеләр.

— Сез теләсә кайда тыпырдамагыз анда, — дип кычкырды әтиләре тәрәзәдән. — Түтәлләрне таптамагыз. Мин сезгә бер кырыйда ком китереп бушаттым, шунда гына уйнагыз!

Ком? Шәһәрдә дә бар ич ул! Монда резин эчәктән түтәлләргә су сиптерергә, шул арада бер-береңә туйганчы «яңгыр яудырып» алырга да була ич. Әтиләре редис, яшел суганны түтәлдән алып ашарга да рөхсәт итте бит әле. Суганны гына тамыры белән йолыкмаска кушты. Парниктагы кыярлар

әле чәчәккә генә бөреләнгән, кишерләре бөтенләй нәзек икән — ашарлыгы да юк. Тукта, әүвәл барлык тирә-юньне карап чыгарга, күршеләр белән танышырга кирәк ләбаса. Әнә ич, якында гына бер абый нидер тук-тук китерә.

Айнур белән Алсу җитәкләшеп шунда таба йөгерделәр. Күрше абый да аларны күреп алды.

— Һай, кунаклар килгән икән ләбаса безгә, — диде ул якты йөз белән. — Кемнәр дип белик инде сезне, дускайлар?

Абыйсы артына поскан Алсу югалып калмады:

— Ә син үзең кем? — дип аваз бирде.

— Минме? — дип көлеп җибәрде абый кеше. — Мин — Касыйм абыегыз. Сез утырып торырга эскәмия ясыйм менә.

— Мин — Айнур. Дәүәни «Айнурҗан» дип тә әйтә.

— Дәүәни белми ич ул, — диде Алсу. — Ул миңа да «Айсылу» дип дәшә.

— Син Айсылу түгелмени? — дип сорады Касыйм абыйсы.

— Түгел. Мин — Алсу. Миңа менә ничә яшь инде, — дип, ул дүрт бармагын тырпайтып күрсәтте.

— Ә мин аңардан олырак,— диде Айнур.

— Ә-тә-тә, син тәмам егет икәнсең ич, — дип үсендерде аны Касыйм абыйсы.

— Мин дә, — дип үзен кыстырды Алсу. — Сезнең кызыгыз бармы?

— Бар. Ул әнисе белән төштән соң киләчәк. Уйнарга иптәшләр табылуына әй шатланыр инде.

— Зурмы ул? — дип сорады Айнур.

— Сезгә сеңел тия.

Касыйм абыйлары, кулына көрәк алып, күз ачып йомганчы ике чокыр казыды. Айнур белән Алсу аның шулай тиз, ипле кайнашуына сокланып карап тордылар. Аннары үзләре дә булыша башлады. Касыйм абыйлары әлеге чокырларга йомры баганалар утырткач, Алсу аларны аудармый тотып торды, Айнур шул арада чокырларны күмде. Касыйм абыйлары багана төпләрен әйбәтләп таптады да агачларның җирдән калкып торган башларына аркылы такта кадаклады.

— Менә хәзер без бергәләп ясаган эскәмиядә утырып ял итәргә дә була, — диде Касыйм абыйлары, бияләен салып. — Яле, ныклыгын сынап карыйк!

Эскәмия нык та, уңайлы да иде.

— Ә безнең эти бияләйсез дә эшли ала, — диде Алсу.

— Безнең эти телевизорны да, үтүкне дә төзәтә,— дип өстәде Айнур.— Үскәч мин дә төзәтәм.

Шулчак, аларны таң калдырып, якында гына:

— Кикери-и-кү-ү-үк! — дигән тавыш яңгырады.

— Абау, кем ул анда? — дип сикереп торды Алсу.

— Сезнең әтәчегез дә бармыни? — дип сорады Айнур.

Җавапны да көтмәстән, икесе дә тавыш килгән якка йөгерде. Өй артындагы тимер чыбыктан үрелгән зур челтәр читлек эчендә кып-кызыл кикрикле, салават күпередәй койрыклы әтәч йөри иде.

— Карале, сакалы да бар, — диде Алсу. — Кызыл сакаллы!

— Анын күзе дә кызылмы әллә? — дип гаҗәпләнде Айнур.

— Юк, сары.

— Юк, сары да, кызыл да!

Алар сырт кабартып бәхәсләшергә генә керешкәндә, яннарына Касыйм абыйлары килеп басты.

— Әтәчебез ошыймы соң сезгә? — дип сорады ул.

— Әтәч сезгә нәрсәгә кирәк? — дип каршы сорау бирде Айнур.

— Йокыдан уятырга. Озак оеп ятсак, түтәлләрне кем йомшартыр, яшелчәләргә кем су сибәр?

— Сәгатегез юкмыни?

— Сәгать нәрсә ул, бер чылтырый да шыпырт кына йөри бирә,— диде Касыйм абыйлары.— Бик арылган булса, анын тавышын колакка да элмисең, әйләнеп кенә ятасың. Ә әтәч син торганчы кат-кат кычкыра, уятмый калмый.

— Кыз-зы-ык, — диде Алсу шаккатып. — Анын чебие дә буламы?

— Юк инде, кеше көлдермә, — диде Айнур, бик белдеклеләнеп. — Әтәч күкәй салмый ич ул.

— Ә мин сине яратмыйм да! — диде ачуы чыккан Алсу.

Айнур сүзне тиз генә икенчегә борды:

— Касыйм абый, безгә әтәч белән уйнарга ярыймы?

— Калач белән сыйласагыз, ярый.

— Ә мин ашаганда сынык-санык калдырмыйм,— диде Алсу.

Айнур, киреләнгән сеңлесенә бераз карап торгач, хәйләсен тапты:

— Сыйламасаң, этәч кычкырмый бит.

Этәч тирәсендә алар бәлки тагын да озаграк юанган булырлар иде, тик игътибарларын бераздан бүтән бер ят тавыш җәлеп итте: «Тук-тук-тук, тук-тук-тук!» Аптырап Касыйм абыйларына карадылар: әллә икенче күршеләре дә нидер ясап маташамы? Тынычсызланган балаларны Касыйм абыйлары шундук аңлап алды.

— Тукран ул, күршекәйләрем. Агачтан корт эзли.

— Тукран?

— Әйе. Күргәнегез дә юкмы әллә үзен?

— Юу-ук.

— Күкене дә белмисезме?

— Юу-у-ук.

— Алайса, сезнең барысы да алда әле. Кошлар сайравын тыңлап рәхәтләнәсегез бар икән монда.

Шул вакыт: «Айнур! Алсу! Кая киттеләр икән инде бу аяклы казалар?!» дип кычкырган тавыш ишетелде. Дәүәниләре эзли чыккан, ахры. Бер дә аларсыз тора алмый инде. Монда да аны ничек каравыллап утырсыннар Айнур белән Алсу?

— Барыгыз, балалар, эти-эниегез югалткандыр сезне, — диде Касыйм абыйлары. Шул арада кунакларның кесәләренә учлап чикләвек тә салды. — Миңа ярдәм итүегез өчен. Рәхмәт, сез булышмасагыз, кичкә кадәр маташкан булыр идем әле.

— Әйе шул, — дип раслады аны Алсу.

— Сезнең белән борчак пешә. Шулай гел кереп йөрегез, яме.

— Ярар, — дип ризалык бирде Айнур.

Алар житәкләшеп бик кәефле төстә үз бакчаларына таба китте. Рәхәт икән дачада. Кая барсаң да, сүз әйтүче юк. Кызыклар гел очрап кына тора. Тик күрше кызының ни исемле икәнен генә оныттылар.

— Әллә кире борылабызмы? — дип сорады Алсу абыйсыннан.

— Әй. Дәүәни чакыра әнә, килгәч, үзеннән сорарбыз әле.

* * *

Төштән соң күрше дачада нәни кызчык белән бер малай да күренде. Үзара сөйләшүләреннән кызчыкның Әлфия, малайның Таһир исемле икәнен беделәр. Озакламый ул малай да нәрсәдер ясарга кереште. Атасы, Касыйм абый кебек, чокыр казыды. Кызчык исә бытылдый-бытылдый һаман шул тирәдә бөтерелде.

Айнур белән Алсу аларны әүвәл тәрәзәдән күзәтеп тордылар. Аннары бакчага чыктылар, бераздан инде күршеләре биләмәсенә дә аяк бастылар. Житү чәчле малай аларны күреп алды да:

— Әлфия, нәнием, кара әле, әнә безгә кемнәр килгән,— диде.— Кунаклар. Айнур абыең белән Алсу апаң.

Нәни кызчык башта ятсынып, ләм-мим дәшми карап торды. Айнур гажәпләнеп Таһир абыйсыннан:

— Ә син безнең исемнәрне кайдан беләсең? — дип сорады.

— Монда бер маэмай йөри иде, шул әйтте.

— Алдакчы! — диде Алсу.— Акмуен сөйләшә белми.

— Белә икән шул. Мин әле аңа сәлам тапшырырга да кушкан идем. Әйттеме сезгә?

Айнурның дачадагы яңа күршеләр белән тизрәк дуслашасы килә иде. Шуңа күрә ул, Таһир абыйсының ярма яруын сизсә дә, күзен дә йоммый:

— Әйтте,— дип раслады.— Тик ул маэмай Муйнак исемле.

— Қара син аны, дөрес бит, әй,— дип килештө күрше абыйлары.

— Син нәрсә ясыйсың?

— Турник.

— Нәрсәгә ул? — дип төпченде Айнур.

— Уйнарга. Аңа ябышып күтәрелгәләсәң, тирбәлеп мәтәлчек атынсаң буең үсә, көчең арта.

— Син таган ясамыйсыңмыни? — дип шыңшый башлады нәни Әлфия.

— Анысы да булыр,— дип тынычландырды Таһир сеңлесен. — Таганны шуңа беркетәбез. Ә син аяк астында буталма, күршеләр белән уйна әнә бар!

Малай чокыр казуын дәвам итте. Алсу белән Әлфия бер читкә китте. Айнур исә Таһир абыйсы янында калды.

— Син безне дә таган атындырасыңмы? — дип сорады ул.

— Атындырырмын.

— Турникта да уйнатасыңмы?

— Билгеле инде.

Әйбәт абый икән, дип уйлады Айнур эченнән. Их, ничек итеп булышырга соң үзенә? Қазышыр иде — чокыры тирән, буе җитмәс шул. Күтәрешер иде — баганалары ай-һай озын! Юан да — астында калуың бар!

Шулчак бакчага Касыйм абыйлары килеп чыкты.

— Бэлеш, минем ярдәмчеләр дә монда икән ләбаса. Кызыма да иптәшләр табылган. Тик әлегә моннанерактарак уйнап торыгыз, яме? Бу тирәдә хәзергә сак булу хәерлерәк!

Айнур шулай да бик ерак китмәде. Олыларның пар багана утыртуын да, аларның башына аркылы тимер беркетүен дә, ул тимергә аркан асуларын да — барысын, барысын да күзәтеп торды. Таган әзер булгач, аңарда беренче атынучы да ул булды. Аннары — Әлфия, Алсу, Таһир абыйсы. Арканның ныклыгын сынар өчен хәтта Касыйм абыйсы да атынып карады.

Таган атынып, Таһир абыйларының турникта уйнавын карап торып, көн узуын сизмәделәр дә. Әлфия күршеләренә тәмам ияләште, аларга тагылып шаярырга, юктан да кызык табып көләргә тотынды.

Эссе басыла төшеп, күләгәләр озыная башлагач, бергәләшеп Айнур белән Алсуларга киттеләр.

— Әни, ашыйсы килә безнең! — дип кычкырды Айнур.

— Әни, бу — күрше кызы Әлфия.

— Ярар, бик әйбәт. Хәзер тәмле мәми бирим әле мин аңа.

Әниләре өстәлгә катык, күмәч, май, йомырка тәбәсе китерде. Айнур белән Алсу бик тәмләп тамак ялгарга керește. Бүлмәне кызыксынып карап чыккач, Әлфия дә табынга утырды. Ул кунакта кыстату йоласын бөтенләй белми иде, ахры, кыю гына катыкка шикәр комы туглый башлады. Чәй ясап куйгач, әниләре:

— Я, ашыкмыйча, иплэп кенэ ашагыз, эчегез, — диде. — Вакытында керүегез эйбэт булды эле. Без кунакка җыенабыз бүген.

— Ә без? — диде Айнур.

— Сез өйдә генә уйнап торыгыз, эллэ кая чыгып йөрмэгез.

Әнисенә тагылырга яраткан Алсу бу юлы бик аптыратмады. Кунак кызы Әлфиядэн яхшысынмады. Ә Айнур өйдә дэ тарланмый. Аулакта ду килеп уйнарлар, ичмаса. Тузан туздырасыз, зыян итэсез, дип сукранучы булмас, рэхэтлэнеп ирек ачарлар.

Тиздэн олылар, киенеп-ясанып, якындагы дусларына киттелэр. Чыгып барганда этилэре:

— Артык дөнья кубармагыз,—дип кисэтте.— Ишегегезне биклэп утырыгыз. Урман эчендэ төрле киек-җэнлек йөри.

— Йөрсен! — дип куйды Алсу.

— Абыегызны тыңлагыз. Ә син, улым, сеңеллэреңә күз-колак бул, без кайтканчы өйдэ син хуҗа.

— Ярый, эти.

Шулай олы кеше булып калуы башта бик ошады Айнурга. Лэкин бу озакка бармады. Бераздан төрле-төрле уеннар уйлап чыгарып, Алсуны да, Әлфияне дэ мавыктырды. Каравылчы өе янына барып, Муйнакны ияртеп килде, песилэре Сары колакны да катнаштырды. Иң ахырда нэүбэт Әлфиялэр этэченэ җитте. Читлекне ачуга, Купшы койрык ишек төбенэ егып авызы белэн куелган эрҗэгэ үзе керде. Айнур шундук эрҗэне утыртып, авызын эскэтер белэн сак кына каплады да кача-поса өйлэренэ йөгерде.

— Менэ хэзер баедык, — диде ул Алсу белэн

Әлфиягә. — Безне йокыдан уятырга әтәчебез, тычкан тотарга мәчебез, дача сакларга этебез бар, ура!

— Ә мин аю-бүредән курыкмыйм,— диде Алсу.

— Шулай да, Муйнак белән күңеллерәк,— диде Айнур.— Ул өрә дә, койрык та болгый белә.

— Ә безнең әтәч, безнең әтәч...—дип авызын ачты Әлфия, әмма нәрсә әйтергә җыенуын онытты да туктап калды. Айнур шунда ук аңа ярдәмгә килде:

— Сезнең әтәч «кикерикүк» дип кычкыра белә.

— Ие шул,— дип куанды Әлфия.— Көндез дә, төнлә дә кычкыра. Ул — тәмлетамак!

Бераздан алар үзләре дә өстәл янына утырыштылар. Күпшы койрык — Айнур кочагында, Муйнак — Алсу итәгендә, Сары колак — Әлфия кулында. Тәбә — җамаякта, катык — чынаяк тәлинкәсендә, күмәч валчыклары — эскәтер өстендә. Әтәч, тарак кикрикләрен шәмрәйтеп, тәкәбберләнеп маташкан арада, Сары колак үз тәлинкәсен ялт иттерде. Муйнак та аңардан күп калышмады, үзе бертуктаусыз койрыгын болгады, табында калган валчыкларны исә Күпшы койрык чүпләп бетерде.

Тәмле сыйдан соң, Сары колак Әлфиягә мырлый-мырлый иркәләнде, елгыр Муйнак, җәлт кенә үрелеп, Алсуның битен ялап алды. Күпшы койрык рәхмәтен «Кикери-и-кү-үк!» дип белдерде.

Кичке эңгер җәелгәндә, бүлмә кинәт караңгыланып китте. Баксалар, ачык тәрәзәдән әллә нинди килбәтсез зур, йонлач бер җан иясе башын сузып карап тора. Авызы-борыны чем-кара, яңаклары коңгыртка тартым, колаклары түм-түгәрәк.

Күпшы койрык шундук Айнур култык астыннан шуып чыкты да «куначa»га — кием шкафы башына

очып менде. Сары колак та аңа иярүне хуп күрде. Бары Муйнак кына ләң-ләң килеп өрә-өрә идәндә борсаланды.

— Аю!

Алсу кычкырмаса да, Айнур чакырылмаган кунакның аюга охшавын чамалаган иде инде. Ишек тә, тәрәзә дә ачык — нишләргә? Ул арада Алсу:

— Абый, куркам,— дип аңа килеп сыланды. Әлфия дә чырылдап елап җибәрде.

Айнур ашыга-ашыга өстәлне кием шкафы янына таба этте, аның өстенә урындык бастырып куйды.

— Тизрәк шкаф башына үрмәләгез!

Нишләргә белми аптыраган Әлфия белән Алсуга ул әүвәл өстәлгә, аннан урындыкка, урындыктан шкаф башына менәргә булышты. Шуннан соң Муйнакны Купшы койрык белән Сары колак янына урнаштырды. Аннары, перәннекләр белән шешәле сөтне алып, Айнур үзе дә шкаф башына үрмәләгәндә, йонлач җанвар ишеккә җиткән иде инде.

Аулакка качып котылгач, Алсу тынычлана төште.

— Абый, сыбызгым буфет алдында калган,— дип пышылдады ул.

— Мактанчыкның гел шулай була инде ул,— дип ачуланды Айнур.

— Ә үзеңнең пистолетың? Ул да шунда ич.

— Шыпырт!

Айнур, өреп эшне бозмасын өчен, Муйнакның авызын учы белән томалады. Сары колак белән Купшы койрык, хәвефне сизепме, аулаккарак постылар. Әмма алты пар күз — Айнур белән кызлар, әтәч, песи һәм маэмай — барысы да ят җанварның

бүлмәдә нишләячәген түземсезлек белән көтә башлады.

— Мы-ы-ы!

Ишектән кергәндә аю менә шулай кычкырды. Аннары, алпан-тилпән атлап, һәр почмакны иснәп чыкты. Бигрәк аңгыра икән, буфет тартмаларын да ача белми. Ашарга эзләгән иде — идәндәге җамаяк буп-буш. Аптырагач, ишек яңагына ышкынып кашына башлады. Шкаф өстендә утыручылар аның шулай җебегәнлеген күреп шактый батырайдылар, куркулары кимегәннән-кими барды.

— Ач, ахры, ул,— дип пышылдады Алсу.

Айнур исә күп уйлап тормады, бер перәннекне идәнгә ыргытты! Аю елдам гына күчтәнәчкә үрелде. Ташлаган перәннекләрнең барысын да һәйбәт кенә җомлап бара башлады.

— Эчәсе килмиме икән аның?

Айнур тиз генә шешәсен ачты да җамаякка турылап сөт агызды. Аның яртысы гына савытка эләкте. Ләкин җанвар сөткә кагылмады. Мы-ы-ы, дип кычкырып куйды да алпан-тилпән янә әйләнгәләргә кереште.

— Бии!

Шкаф башындагы качаклар шаккатты. Айнурның уяулыгы кимүдән файдаланып, Муйнак ләң-ләң өреп җибәрде, аннан күреп, әтәчкә дә җан керде:

— Кикери-и-кү-үк!

Сары колак исә сикереп төште дә идәнгә чәчрәгән сөтне чәпелдәтеп ялый башлады. Купшы койрык, кыт-кыт килеп, канатларын какты. Муйнак яхшатланып бию көенә сикеренергә тотынды. Каушавы басылган Айнур сәер кунакның кыяфәтен

аюныкына да, кешенекенә дә охшатты. Ят җанварның әкәмәт якларын хәзер инде Алсу да абайлады.

— Абый,— дип пышылдады ул,— бу аю циркта-гыга охшамаган, иеме? Аягы озынрак. Тәпиенә әллә чүпрәк ураган инде?

— Белмим. Чын аю түгел, ахры, ул.

Айнур озак баш ватып тормады, тәвәккәлләде дә җанварның өстенә сикерде. Алсу белән Әлфия дә аңардан калышмаска тырышты.

Аю, аларның өчесен берьюлы күтәреп, ишекле-түрле чабып йөрде, башын болгый-болгый «Мы-ы-ы» дип кычкырды, аннары уфылдап идәнгә ауды. Шау-гөр килгән Айнурлар да аның белән бергә идәнгә тәгәрәделәр.

Алсу белән Әлфия аякка торып баскан арада, «аю» тиресен салып, Таһир абыйларына әверелмәсенме!

— Карагыз әле бу бөтерчекләргә, — диде ул елмаеп. — Аюны да ат итеп уйныйлар. Бигрәк кыю, ахры, сез?

— Ие,— диде Алсу.— Мин тамчы да, тамчы да курыкмадым.

— Мин дә сүрләмәдем,— дип кушылды Әлфия.

Айнур әүвәл шкаф башына, аннары өстәл өстендә торган урындыкка карап алды да көлеп җибәрде. Бик батыр шул алар, бик батыр!

* * *

Бүлмәдә — җил. Ишектән керә дә, пәрдәләрне җилфер-җилфер селкетеп, тәрәзәдән чыга. Юл уңаенда Айнурның битләреннән сыйпап: «Син егет кеше, курчак уйнаучы сеңелләреңне караулап өйдә

генә ятма, әйдә бакчага чык, мин сине ястык болытка утыртып, күктә очыртып йөртермен», — дип пышылдый.

Айнур әтисе шүрлек ясарга әзерләп куйган такталар өстендә аякларын тирбәтеп утыра. Аннары кулларын җәеп, кош канатыдай, җилпи башлый. Һава, су кебек, куера, Айнур утырган җиреннән аерылып, өскә күтәрелә, ачык тәрәзә аша урамга чыгып китә. Аяклары, суда йөзгән шикелле уйнаклап, биеккә менеп китәргә булыша.

— Ә мин очам!— дип кычкыра ул берзаман кызларга.

Алсу белән Әлфия күтәрелеп аңа карыйлар да шаккаталар: абыйлары, чыннан да, күктәге болыттай, һавада йөзә. Кошныкы кебек канаты да, самолетныкы кебек пропеллеры да юк. Алсу, шундук уенчыкларын атып бәреп, кәҗәләнә башлый:

— Минем дә очасым килә!

— Ашыкма, нәнием. Башта мин әйбәтләп сынап карыйм әле.

— Юк инде, — ди Алсу киреләнеп. — Я икәү бергә очыйк, я син дә җиргә төш!

— Бергә ярамый,— дип аңлата Айнур.— Элек үзем остарыйм әле, аннары сезне дә өйрәтермен.

— Әйем. Минем дә хәзер үк очасым килә.

— Ә егылып төшсәк? — дип куркытмакчы була аны абыйсы.

— Булсын!

— Ярамый. Имгәнүең бар.

Айнур сеңлесенә бүтән колак салмый. Суда йөзгән шикелле, кушаягы белән һаваны ишә-ишә, тәрәзә аша тышка чыгып китә. Башта, егылып төшүдән

шүрләп, биек күтәрелми, түтәлләр өстендә генә әйләнә. Аннары, кыюлана барып, өй түбәсе югарылыгына менә. Аякларын бер селкетеп, бөтен гәүдәсе белән киерелүе була, сабан тургаедай өскә атыла. Икенче хәрәкәт ясап, алан өстеннән очып үтә. Дачаларга уздырылган электр чыбыгы да, телевизор антенналары да аста кала. Айнур, бераз иялəшә төшкәч, тагын да өскәрәк күтәрелә, һава ерып барудан күкрәгенә әлегәчә татылмаган рәхәтлек тула. Қаен ябалдашлары югарыдан сизелер-сизелмәс кенә тирбәлгән яшел болыт кебек күренә. Қул сузымы җирдә җәелеп яткан күл көзгедәй ялтырый, урман артында исә биек ак ташпулатлар тезелешеп киткән. Алар яши торган кала ич бу. Нинди рәхәт, нинди күңелле икән ул очу. Мондый биеклектән тукраннар да, чын аю-бүреләр дә уч төбендәгедәй әллә кайдан күзгә чалына. Қош кебек өсләренә генә очып төшәсең дә башларыннан сыйпап үтәсең. Қалага да очып кына кайтасың. Өйрәтәчәк, Алсу белән Әлфияне дә, һичшиксез, өйрәтәчәк ул очарга!

Чү! Алсулар бакчадан аңа кул болгыйлар түгелме соң? Әллә эти-әниләре кунактан кайтып җиткәнме? Тукта, һәммәсе хафаланмасын, тизрәк яннарына төшәргә кирәк!

Айнур аякларын бер кыймылдата да, канатларын җәйгән күгәрчен сыман, салмак кына түбәнәя башлый. Һавада тирбәлә-тирбәлә, бал корты, төклетура кебек безелдәп, икенче каттагы тәрәзә аша өйгә очып керә. Әмма тизлеген вакытында киметә алмыйча, ниндидер каты нәрсәгә шапылдап килеп бәрелә...

Қүзен ачса, ул чыннан да идәндә ята икән. Бул-

мәдә ут яна, әти-әниләре радио тыңлый. Алсу ялгызы гына вентилятор янында чәен суытып утыра. Абыйсының аңлы-миңле як-ягына каранауын күргәч, ул кулларын чәбәкли-чәбәкли:

— Егылды, йокы чүлмәге егылды! — дип кычкырды.

Айнур эндәшмәде. Аның яңадан күккә күтәреләсе, сеңлесен дә очарга өйрәтәсе килә иде.

ЯҢА УЕН

Чокыр ярында малайлар белән тегермән ясап уйныйбыз. Улак сыман итеп юл уеп төшәбез дә, шул юл өстенә чыра казыклар кагып, нәни чатыр әмәллибез. Аның уртасына нечкә чыбыклардан «иләк» үреп куябыз. Яр башыннан агызып җибәргән туфракның эрерәк бөртекләре әнә шунда «кибәк»кә кала, «ончасы» исә алдан ук әзерләп куелган эрекмән капчыкларга коела. Тегермәннәрне уздырыштан ясаганлыктан, аларның нинди генә булмый да колашалардан туфракның нинди генә акмый!

Менә шулай онытылып уйнап ятканда яныбызга класс җитәкчебез Рәҗәп абый килеп туктады. «Ай-яй-яй! Уенның тәмлесе менә кайда икән», дип тезеп китәчәк инде ул хәзер. Гаҗәп, нигәдер ашыкмый әле бүген. Яр башына чүмәште дә безнең балчык агызганны карап тора башлады.

— Кулларыгыз алтын икән ләбаса,— диде ул бераздан. — Әмирнеке җил тегермәне, ахры, үзе яр башында, канатлары да бар.

— Һи, әйләнми лә алар,— дип дәрәҗәмне төшерергә ашыкты көнче Мөдәррис.

Җәмил киң күңелле иде, мине яклап:

— Җил исми ич, — диде.

— Кулларыгыз алтын да, осталыгыгыз уенга гына исраф ителә шул, — диде Рәҗәп абый. — Башкаларга да кирәкле, файдалы нәрсәләр ясасагыз иде сез.

— Нәрсә ясыйк соң? — диде Мөдәррис.

— Туган як музеена авыл макетын әмәлләп куясы иде.

— Кала музеендагы шикелленеме? — дип сорадым мин.

— Безнең хәлдән килми лә ул,— диде Җәмил, бәласеннән башаяк, дигән сыманрак.

— Ә бәлки киләдер,— дидем мин Җәмилгә.— Син макетның нәрсә икәнен белмисең дә ич әле.

Мөдәррис дәшмәде. Билгеле инде, аның шәһәргә гомер барганы юк, музейдагы шырпы тартмасы кадәрле генә матур өйләрне, мәчет, тегермәннәрне кайдан күрсен ди ул! Ә мин менә алар тирәсендә әллә ничә мәртәбә әйләнеп йөрдем. Әллә ничә тапкыр кызыгып карап тордым. Менә шуларны истә тотып ясаганга күрә дә, минем тегермәнем иптәшләремнекеннән шәбрәк, күреклерәк иде. Иплерәк тә эшли. Әгәр авыл макетын да ясап карасак? Шәһәр музеендагы нәни өйләр бервакыт мине төшкә кереп тә аптыраткан иде әле. Хәзер дә онытмадым. Бик тырышсам...

Рәҗәп абый, уемны белгәндәй, миңа күз салды да:

— Әмир булдыра инде аны,— диде.— Ә сез аңа ярдәм итәрсез.

Иптәшләрем өнсез калды. Кеше әмерен үтәүне

Мөдәрриснең җене сөйми. Үз башыннан чыгарып мәш килергә генә ярата ул. Ә минем аны ничек тә булса, нәрсәдә дә булса узасым килә. Моңа бүген менә җае да чыгып тора.

— Кайчан ясарга соң аны? — дидем мин Рәҗәп абыйга.

— Теләсәгез менә хәзер тотынабыз. Кирәк-яракларның барын да әзерләп куйдым инде мин.

Мөдәррис исе китмәгәндәй кылана. Беләм инде, ялындырасы килә. Ә Җәмил икеләнә. Рәҗәп абый тәкъдиме, күрәсең, аның да күңелен кытыклаган.

Торып чалбарымны кактым да дусларыма эндәштем:

— Чокыр буе качмас әле, мондагы уенны теләсә кайчан уйнап була ич. Әйдәгез, малайлар, яңасын өйрәник!

Минем арттан Җәмил дә яр башына үрмәләде. Ә Мөдәррис кымшанмады да. Һаман тегермәнен рәтләгән булып маташа.

—Мен инде тизрәк!

— Әй,—диде ул миңа ачулы тавыш белән.

Иярмәсә, кирәге бар иде. Аннан башка да дөнья җимерелмәс әле, дип китәргә кузгалган гына идек, Мөдәррис:

— Әмир, кил әле монда! — дип кычкырды.

Мин кире килгәч, ул Рәҗәп абыйга ишеттермичә:

— Син нәрсә гел кеше җырын җырлыйсың? — дип пышылдады.— Әгәр укытучыга иярсәң, дуслыгыбыз бетә.

— Үзеңә кара.

— Йодрык белән сыйлавым да бар.

Берни булса, шулай көче белән куркыта ул. Ачуым кабарса да, бүген мин аның белән бәйләнешеп тормадым. Түбәтәйне кыңгыр салдым да Рәҗәп абыйга тагылдым.

— Бүтән балаларга әйтеп тормасак, үзебез генә ерып чыгарбыз микән? — диде ул.

— Булдырырбы-ы-ыз! Кирәкми! — дидек без Җәмил белән беравыздан.

Мәктәптән рулетка, терекөмешле тигезләгеч, компас, турыпочмаклы сызгыч, тагын бүтән кирәкле нәрсәләрне алып чыктык та тау башына менеп киттек. Югарыдан көяз каеннар, салбыр таллар, алар арасындагы өйләрнең әләм төсле кызыл түбәләре күренә иде. Шунда ук ярларына керәшәләр оялаган Чирмешән. Елганың зәңгәр тасмасы авылыбызны пута сыман урап алган. Күңелгә якын күренешкә күзләребезне шар ачып бераз карап торгач, эшкә керештек. Үрнең иң биек ноктасыннан аска таба үлчәп төшә башладык. Мин терекөмешле тигезләгеч белән горизонталь сызыкны билгелим, Җәмил бер метр арада тауның күпме сөзәкләнүен үлчи, Рәҗәп абый без әйткән саннарны дәфтәренә язып бара иде. Әнә шулай метр арты метр болынга кадәр төштек, аннары урамнарны, Чирмешән елгасы ярларын, су тирәнлеген, аръякны үлчи-үлчи мәктәпкә килеп җиттек. Төшкә таба авылыбыз урнашкан үзәнлекнең кабарынкы картасы әзер иде инде. Чын үлчәмнәрне мең тапкыр киметеп, урам, чокыр, тауларны макет куяр өчен әзерләнгән өстәл өстенә күчереп ясыйсы гына калды. Тик без бу эшне иртәгә башкарырга ниятләдек.

Чирмешән буен үлчәп ыгы-зыгы килгәндә, Мөдәррис күзгә чалынды. Хәзер инде ул безнең мыдыр-мыдыр сөйләшеп, мавыгып эшләп йөрүебезгә кызыга да иде бугай. Тик үзе килеп кушылырга гарьләнепме, кырыйдан гына карап узды.

Мин юл буе хыялланып кайттым. Өйдә дә бар уем шул макет тирәсендә бөтерелде. Кеп-кечкенә мәйданчыкка кизләү буеның яшел куакларын, атаудагы җимеш бакчасын ничек ясарга? Ә күлне? Өйләрнең челтәрле кыекларын, сырлы кәрнизләрен, бизәкле капкаларын кечерәйтеп гәүдәләндергәндә бөтен матурлыгы юкка чыкмасмы? Авылыбызның яме булган сиртмәле коеларны, янгын каланчасын ничек корырга? Музейда бит аларны бөтен авыл халкы караячак, сынатырга ярамый!...

Бу уйлар йокыга киткәч тә тынгылык бирмәде миңа. Төне буе төшемә кереп йөдәтте. Аннары... имеш, Мөдәррис белән Җәмил, макетны бөтенләй онытып, яңа тегермән коралар икән. Минем йомычкаларны да үзләренә алып бетергәннәр. Алардан канат ясаганнар. Тегермәннәре башына байрак элгәннәр...

Бу шомлы төштән соң мин инде йокыдан тәмам айныдым. Рәҗәп абый әйткән вакыттан байтак элек мәктәпкә элдерттем. Шунысы гаҗәп, Җәмил анда миннән дә алдарак барып җитеп, Рәҗәп абыйны көтеп утыра иде инде.

Бик кызыклы эш булып чыкты әле бу макет ясау. Җәмил өстәл читенә кагарга такталар әзерли башлады. Мин елга буеннан үзле балчык казып алып килдем. Аннары үзем әзерләгән балчык измәсен өстәл өстенә җәеп, авылыбыз утырган иңкүлек-

не, аның бер кырыеннан күтәрелгән үрне ясарга кирәк иде.

Шул вакыт әллә нинди шытырдау тавышы ишетеп, башымны күтәрдем. Койма артында кемдер йөри, әмма үзе күренми иде.

— Мөдәррис ул,— диде Җәмил көлеп.— Ярыктан танып калдым.

Аннары дустым куаклар әзерләргә тотынды. Мин, Мөдәррис күзен кыздырып аяк чалырга йөрми микән, дип борчылсам да, балчык белән мәш килүемне дәвам иттем.

Макет дөрес һәм охшатып ясалса, аңа караган кеше авылыбызны һәм ул урнашкан үзәнлекне бер күрүдән үк танырга тиеш иде. Димәк, монда һәр нәрсә: тавы да, елгасы да, башкалары да үз урынында булу кирәк. Шунлыктан миңа җиде кат үлчәп, бер кисәргә — һәр җыерчыкны, һәр уентыны чамалап кына, сакланып кына ясарга туры килде. Маңгаема бөрчек-бөрчек тир бәреп чыкты, җиңнәрем сызганып куелган көе дә балчыкка буялып бетте. Иң соңыннан нәни калак белән бормалы Чирмешән тасмасын уеп чыктым.

— У-һу-у, эшләр куәтле икән сезнең монда! — диде шулчак әллә кайдан мәктәп ишегалдына килеп кергән Рәҗәп абый. — Мине көтеп тә тормагансыз.

— Тизрәк өлгертергә ашыктык,— диде Җәмил.

— Әһә. Кара әле бу тиктормасны, кулы ябыша-а-а!

Җәмил бу юлы да укытучыбыз сүзенә кушылып китте:

— Әмир бик оста ул, күптән тотынасы калган бу эшкә.

Мондый мактаулардан уңайсызланып башымны түбән идем. Колакларыма кадәр кызыша башлады. Әмма бик рәхәт иде миңа. Иптәшем исә ялт-йолт карангалады да борынын салындырды. Шулчак исемә килеп:

— Җәмил дә тырышты, бар җирне җентекләп үлчәргә ярдәм итте,— дидем, аның да күңелен табарга теләп.

— Ерактан карасаң, нәкъ шундый шул безнең авыл,— диде Рәҗәп абый.— Су буенда иптәшегез Мөдәррис тә нидер корып ята әле. Сезнеке кебегрәкне.

— Мөдәррис? — дип сорадым гаҗәпләнеп.

Әмма Рәҗәп абый хәбәренә Җәмил игътибар итмәде.

— Әле макетны буйыйсы, күп җирләренә агачлар утыртасы бар,— диде ул.

— Йорт-җир, каралты-кураларны да ясарга кирәк,— дип өстәде Рәҗәп абый.

— Анысын да үзебез генә этмәллибезме?

— Башкаларны да катнаштыру хәерле,— диде укытучыбыз.— Бусы әле хезмәтнең башы гына.

Аннары без, киптерер өчен, макетны күләгәгә куйдык.

— Болай булгач, эшләр гөрли икән безнең,— дип сөенде Рәҗәп абый.— Калганын киләсе якшәмбедә ясап бетерербез инде.

— Ә без аны иртәгә үзебез генә дә...— дип авыз ачкан идем дә әйтеп бетерми туктап калдым. Нәрсәгә күпсенәм соң әле мин бу эшне башкалардан?

Җыелсыннар, барыбыз бергә ясарбыз. Музей кадәр музейны Әмир белән Җәмил генә оештырмас ич инде. Бер-ике бөртектән генә ботка пешми. Ә макет әзерләүгә безнең көч күбрәк керү хәзердән үк билгеле. Мактaлдык та менә. Әйе, бу инде үз күңелебезне күрер өчен генә яр буенда тегермән ясап маташу түгел. Бөтен авыл өчен тырышу. Ярый әле Рәҗәп абый бу эшне беренче безгә кушты!

Укытучыбыз белән саубуллашканнан соң, Чирмешән яры буйлап кайту юлына чыктык. Менә шунда без бая Рәҗәп абый телгә алган хәйран күренешкә тап булдык. Борылышларның берсендә, комлыкта Мөдәррис чынлап та безнең макетны хәтерләткән нәрсә ясап ята иде.

Бер юан тал куышына яшеренеп, хәтсез күзәтеп тордык малайны. Шул арада яңгыр ява башлады. Кинәт килде дә чиләкләп коепмы-коя. Елгада су бик тиз артып, озакламый ул Мөдәррис корылмасына да килеп җитте һәм аны ишә дә башлады. Иптәшебез, тирәсенә ком өеп, корылмасын саклап калырга тырышты. Шулай тыз-быз килеп, суга төшкән тавык төсле чыланды. Әмма елгада ташкын күтәрелгәннән-күтәрелеп, бераздан барыбер Мөдәрриснең бик оста ясалган уенчык өйләрен ишеп, күмеп китте. Иптәшебез яр өстенә үрмәләп менсә дә, ышыкланыр урын эзләмәде. Әле генә агым юкка чыгарган корылмасы турысына төбәлеп, катып калды.

Әйтерсең миңа да нидер булды, аңа булган ачуым таралды да бетте.

— Кызганыч! — дип пышылдады Җәмил.

— Әйе шул, авызы пеште менә.

Яңгыр туктауга, Мөдәррис ни өчендер өенә

түгел, мәктәпкә таба китте. Шикләнгәнлектән, кача-поса без дә аңа иярдек.

Ишегалдына кергәч, ул туп-туры макет куелган лапаска таба юнәлде. Өстәл янына килеп, без ясаган үзәнлекне бик озак карап торды. Аннары, агач саплы пәкесен чыгарып, бер шакмактан нәни таякчыклар телергә кереште. Тын да алмый капка ярыгыннан күзәтәбез: аларны кисеп тигезләде, баш-башларын уйды...

Шыгыр-р-р!

Арт капка ачылды да ишегалдында мәктәп каравылчысы пәйда булды. Мөдәррис башта торакташтай катып калды, аннары пәкесен кесәсенә тыгып, лапаска ышыклана-ышыклана, урам капкасына таба йөгерде. Аңа күренмәс өчен, без утын өеме артына постык.

Иптәшебез туп кебек тышка атылып килеп чыкканнан соң тизлеген киметте, бераздан бөтенләй туктап артына борылып карады. Тик кире әйләнеп кайтмады, теләр-теләмәс кенә өенә таба атлады. Ул күздән югалгач, Җәмил:

— Нишләмәкче булды икән Мөдәррис? — диде.

— Безнеке шикелле макет ясамакчыдыр. Кызыгып карап йөрүен бая ук чамаладык ич.

— Әгәр макетны бозарга уйлаган булса?

— Тимәде ич әнә.

— Каравылчы гына өркеткәндер аны.

— Белмим,—дидем мин.— Бүген монда бүтән аяк басмас инде ул. Кич булды. Аннары кеше күзенә чалынудан да сакланыр.

— Кара әле, үзе телеп ясаган таякчыкларын да кесәсенә салдымы Мөдәррис?

— Күрмәдем.

— Менә пешмәгәннәр, шуны да абайламадык, ә? — диде Җәмил пошынып.— Мөдәррис берәр бәла чыгармасын тагын. Әллә иртәгә мәктәпкә таңнан ук киләбезме?

— Килик!

Җәмил шиге миңа да йокты. Өйгә кайткач, күңелемне корт кимерә башлады. Әгәр Мөдәррис үчләшсә? Үз эше барып чыкмаганга ачуы килеп, безгә аяк чалса? Макетыбызны аулакта зир-зәбәр китерсә? Класска гына кертеп куясыбыз калган икән аны. Лапаста агач юнып маташканда иптәшебезнең өстенә барып керсәк тә, уңган булыр идек. Шунда тотылгач, Мөдәрриснең этлек эшләргә базмаячагы хак иде. Ә без качып кына күзәтеп маташтык. Юкка...

Бу юлы мин йокыдан бик иртә уяндым. Әйтәм ич, йокым йокыга охшамады, төне буе һаман шул макет белән саташып изаландым. Әти: «Авырмыймы икән бу бала?» — дип, маңгаема кулын куеп карады, әни: «Бушанып керәсеңме әллә, улым?» дип, мине тышка чыгарга өндәде. Әкәмәт бу олылар, әйтерсең малайларның бар кайгысы, бар тынычсызлануы чир белән кысталудан гына!

Җәмилне йокыдан үзем килеп уяттым. Ул тамагына кабар-капмас, мәктәпкә чыгып йөгердек. Тизрәк макетны барларга.

Лапаска килеп кергәч, таң калдык: макетыбыз исән-сау гына түгел, каш куелган йөзектәй, тагын да ямьләнеп, матураеп киткән. Тау башына җил тегермәне менеп кунаклаган, ә Чирмешән буена су тегермәне бурап куелган. Билгеле, без аларны кем

ясавына тамчы да шикләнмәдек. Тик кайчан өлгергән ул моңа?

Башларыбызны чайкап, класска кереп китәргә җыенганда гына алдыбызга кәгазь күгәрчен очып килеп төште. Артыбызга борылсак, лапасның каралгы почмагындагы иске парталар артыннан Мөдәррис карап тора.

— Нихәл, йокы чүлмәкләре? — диде ул авызын ерып.— Экскурсиягә килдегезме?

— Абау, куркыттың! — диде Җәмил.— Нишлисең син монда?

— Тире җыеп көн эшлим. Күрмисеңмени?

— Күрдек, бик әйбәт булган бу,— дидем мин макетка ишарәләп.— Рәҗәп абый юкка гына күмәкләп ясарга кушмаган икән аны.

Мөдәррис ышанып бетмичә:

— Укытучы абый бу эшкә мине дә катнаштырырга каршы түгел, алайса? — дип сорады.

— Түгел, билгеле. Тик ул тегермәннәрне генә телгә алмаган иде. Авылыбызда юк ич алар.

— Алар элек булган,— диде Мөдәррис җанланып.— Музейда борынгы тормышны да күрсәтәләр икән ич. Димәк, тегермәнсез ярамый инде. Салам башлы өйләрне, тимерче алачыгын, ябык ындырны да ясарга кирәк әле.

— У-у-у, аларның барысын ничек ясап бетерербез,— дип аптырады Җәмил.— Монда сыярмы соң алар?

— Сыяр,— дидем мин ышанычлы төстә.— Бергәләп тотынгач, җае табылыр. Күбәү ич без хәзер!

ТУКРАН ТӘҮБӘСЕ

Җәмилгә юк өчен дә бәйләнәләр инде. Бармакларын юри буямый лабаса ул карага. Күлмәк итәген дә юри чалбарыннан чыгарып йөрми. Язу язганда — ашыга. Уенның тәмен белеп уйнаганда — онытылып китә. Бөтен бәласе шул.

— Ә син кабаланма, — дип киңәш бирә Динә. — Әмир әнә ашыкмый. Шуңа күрә буялмый да. Югыйсә безнең класс синең аркада чисталык буенча артта сөйрәләчәк.

Тырнаклары тиз үсүенә үзе дә гаҗәпләнә Җәмил. Атнасына әллә ике мәртәбә кисәргә шуларны? Динә тикшерә башлагач кына исенә төшә шул. Тикшергән саен ялына Җәмил:

— Бүген журналга билге куеп торма инде. Иртәгә мин аларны төптән үк кисеп киләм. Ант менә!

— Синең антларыңны беләм, — ди Динә. — Әйтәсең дә шундук онытасың.

— Тәүбә-тәүбә, онытмыйм. Иртәгә үк ялт иттерәм.

Алар тирәсенә авыз ерып классташлары җыела. Динә исә кашын гына җыера:

— Фу-у, тукран тәүбәсе!

Аннары санитар журналга Җәмил исеме турысына аккош муены кадәр «икеле» утырта.

— Ай-йай, симез! — дип көлә Гәрәй.

— Бу безнең бөтен «дүртле», «бишле»ләрне бер үзе бәреп ега! — дип хихылдый тагын кемдер.

Ачуы кабара Җәмилнең. Сипкелле борынына тир бәреп чыга, колагына кадәр кызарына. Юк,

Динә «икеле» куйганга түгел. Иптәшләре уртәүгә йөрәге кысыла аның. Җан дусты саналган Әмир дә аны яклап ник бер сүз әйтсен ичмасам. Әле кайчан гына нишләсәләр дә бергә булалар иде. Хәзер ташлады. Ул да Динәне үгетләсә, бәлки тыңлаган булыр иде кызый. Ә хәзер ялынуыңа үкенерлек. Класс җитәкчесе дә күрәчәк «икеле»не. Бер генә булса икән ул «аккош муеннары»!

Җәмил дәрес башлангач та иптәшенә үпкәләүдән туктамады. Әмир белән авылның бер очында, күршедә генә яшиләр. Мәктәпкә бергә йөриләр. Барлык уеннары уртак. Әле кайчан гына җиту тырнаклары да, чалбар эченнән сытылып чыккан күлмәк итәкләре дә пар була торган иде. Бүген менә санитар журналына Әмиргә «бишле» куйдылар, ә Җәмилгә...

Җәмил бүген мәктәпкә стена сәгатенең эчен сүтеп алып килгән иде. Шундый кызык: тешле-тешле бер нәни тәгәрмәчен партага бастырып тәгәрәтсәң, күчәренә тоташкан икенчесе дә әйләнә башлый. Икенчесе өченчесен, анысы дүртенчесен хәрәкәткә китерә. Ә парта өстендә нәни тәгәрмәченең теш эзләре чылбыр кебек тезелеп кала. Матур! Өстәвенә зер-зер әйләнүләреннән серле тавышлар чыга — нәни фабрика эшләп торамыни!

Класста шуның белән уйнаса, бөтен малайларны үзе тирәсенә җыясы иде Җәмил. «Кая, мин дә йөртеп карыйм әле!» дип теңкәсенә тиячәкләр. Тик «сәгатен» тотып карауны ул иң якын иптәшләренә генә рөхсәт итәсе иде. Беренче нәүбәттә, билгеле инде, Әмиргә. Ә хәзер... Хәзер тәнәфестә уенчыгын портфеленнән дә чыгармады. Дәрес башлангач кы-

на парта астында зер-зер китереп йөртә башлады. Күршесе Әмир ишетерлек, әмма күрмәслек итеп.

Әүвәл Әмир колакларын шомрайтты, аннары ул Җәмилгә борылып:

— Син нәрсә зырылдатасың? — дип пышылдады.

Билгеле инде, Җәмил ләм-мим эндәшмәде. Парта астына кулын сузып тәгәрмәчләрне әйләндерә бирде. Серле тавышка Әмир кыбырсый ук башлады. Укытучы аңа:

— Әмир, тик кенә утыр әле! — дип кисәтү ясады.

Җәмил гөнаһсыз кыяфәттә катып калды, аннары астыртын гына елмайды. Һаман ул гына гаепле булырга димәгән, башкаларны да оялтсыннар! Үзе шул арада «сәгатен» кешегә сиздермичә генә портфеленә тыгып куйды.

Бу соңгы дәрес иде. Кыңгырау шалтырауга, укучылар ашыга-ашыга китап-дәфтәрләрен җыештыра башлады. Тик укытучы кинәт купкан ыгы-зыгыны басып:

— Балалар, туктагыз әле! — диде.— Минем сезгә бер-ике сүзем бар. Чисталык, пөхтәлек турында.

Шау-шу тынды. Бөтенесе кире урынына утырды. Җәмил, үзенең тагын телгә алыначагын тоеп, бөрешеп калды. Аннары берәү дә уйламаганда сикереп торды да:

— Апа, мин онытканмын гына, бүген өйгә кайткач ук тырнакларымны кисеп куям,— диде.

Классташлары көлеп җибәрде. Динә тагын «тукран тәүбәсе» дип мыскыл итте, ахры. Әмма кычкырып әйтмәде. Җәмил: «Акыл өйрәтергә кирәк әле моңа», — дип уйлап куйды.

Укытучы журналны ачып, укучыларның кайсын мактап, кайсын оялтып чыкты да:

— Шапшакларны ата-аналар җыелышына чакырмый ярамас! — диде.

Бүген Җәмил классны җыештыруда дежур иде. Әмир һәм аларга махсус беркетелгән Динә белән бергә. Бүлмә бушауга, Динә су, чүпрәкләр алып килергә йөгерде. Малайлар парталарны классның бер ягына күчерә башлады. Шулчак Әмир:

— Бая уйнаган нәрсәңне күрсәт әле? — дип үтенде.

Җәмилнең иптәшен ялындыртасы килә иде. Шарт куеп күрсәтсә генә инде. Әйтик, гел аны якларга сүз бирсен!

— Аннары, уйнап та карыйм әле, дип аптыратыр идең бугай.

— Бик кызык уенчыкмыни соң?

— Кызык. Андый әйбернең әле берегездә дә булганы юк! — диде Җәмил горур гына. — Зерелдәгән матур тавышы, нәни энҗеләр кебек эз калдыруы гына да ни тора.

— Я күрсәт инде?

— Мин аны чын дусларга гына күрсәтә алам. Уйнарга да шуларга гына биреп торачакмын.

— Мине дус итмисеңмени? — дип гаҗәпләнде Әмир.

— Үзең ич...

— Нәрсә «үзем»?

— Миңа кеше бәйләнгәндә, үзеңә кагылмауларына шатланып, шуңа масаеп торасың. Кая ул мине яклау! Дус шундый буламы?

— Ә-э,— дип елмайды Әмир.— Ничек яклыйм инде, тырнакларың атаман шикелле үссен дә!

— Әле кайчан гына үзеңнең дә шундый иде.

— Әти миңа нәни пәке бүләк итте ич. Беләсеңме, ул нинди?

— Нинди?

— Чәнти бармак кадәрле генә. Тырнак кискече дә бар. Черт-черт итеп, күз ачып йомганчы «атаман»нарыңны каба да өзә.

— Яле күрсәт?

— Өйдә калды. Мәктәпкә алып йөрергә куркам, югалтуым бар.

— Әйтәм аны тырнакларын ыспай йөртә башлады.— Җәмил, ачуы килеп, партаның үзе тоткан башын дырк иттереп идәнгә ташлады. Парта эчендәге портфель шапылдап идәнгә төште, андагы китап-дәфтәрләр аяк астына чәчелеп китте.

— Син нәрсә? — диде Әмир, таң калып.

Җәмил портфель иясен шелтәли башлады:

— Пешмәгән, шуны бикләп тә куймаган икән. Санитар булып йөргән була тагын.— Аннары иптәшенә борылып эндәште: — Әйдә җыеш инде, килеп керүе бар.

Динәнең китап-дәфтәрләрен җыйган арада, Җәмил санитар журналын күреп алды. Шундук башында бер уй туып:

— Әмир, син мине сатмассыңмы? — дип сорады.

— Кайдан килде әле башыңа андый сорау?

— Син миңа дусмы?

— Дус.

— Ә дусны сатарга ярамый. Шулай ич?

— Шулай,— диде Әмир.

— Сатмаска ант итсәң, бер сер әйтәм үзеңә.

— Әйт.

— Башта ант ит.

— Сереңбүтәннәргә зыян сала торган түгелме соң?

— Юк инде.

— Ант!

— Вәгъдә иман. Кара аны! — диде Җәмил.— Мин хәзер бу санитар журналын яшереп куям.

— Әгәр Динә сизеп калса?

— Сизмәс. Син серне ачмагач, кайдан белсен ул мин яшергәнне?

— Ә класс? Журналсыз ярамый ич?

— Яңасын ачырбыз. Монысында сиңа да, миңа да «икеле»ләр чәпәлгән. Яшерсәк, ата-аналар җыелышында безне хур итә алмаслар. Моннан соң пөхтә йөрербез..

Әмир тагын ни дә булса әйткәнче, Җәмил якягына ялт-йолт каранды да, элеге журналны икегә бөкләп, стенага беркетелгән класс тактасы артына кертеп җибәрде. Аннары бик эшлекле төстә тагын парталар күчерергә тотынды.

Санитар журналының югалуы иртәгәсен бөтен класска билгеле булды. Шапшакларга шикләнеп карасалар да, тотылмаган кешене ничек гаеплисең? Динә кайда жуйгандыр бит әле аны. Бәлки табып та куяр?!

Әмма журнал ике-өч көннән соң да табылмады. Яңаны ачарга туры килде. Җәмил канатланып китеп, читләре бөгәрләнгән, тышлары буялган дәфтәрләрен берәм-берәм юкка чыгарды. Бөтен предметлардан яңаларны башлады. Чирек уртасында! Мо-

ның өчен укытучы аны мактамады, билгеле, әмма малайның өс-башын, бит-кулларын пычратмыйчарак йөрергә тырышуын күреп, каты бәрелүдән үзен тыеп калды.

Җәмилнең шатлыгы йөрәгенә сыеп бетмәде, тышка бәреп чыкты хәтта. Күңеле кытыкланып торганга, дәресләр тәмамлангач, коридорга йөгереп чыкты да үзенә әле беркөн генә «шапшак» дип көлеп карап торган берничә малайның башларына портфеле белән кундырмасынмы! Шаярып кына селтәнгән иде, әллә ялгыш катырак тигән, шуннан соң бөтенесе аңа ябырылды. Чорнап та алдылар, бәреп егып, өстенә дә менеп атландылар. Идәннең бар тузанын иярткәч киеме ничек ак-пакь калсын инде? Җитмәсә әле: «Кешегә бүтән тимисеңме?» — дип каныктылар, тәүбә иттерделәр. Ә күршесе, партадашы Әмир, бу юлы да аңа булышырга ашыкмады. Җәмил моны күңеленә салып куйды, ләкин битәрләп һични әйтмәде. Үзенә ябырылган классташларын мәзәк хәлгә төшерүне уйлап кына баш ватты. Уйлый торгач тапты!

Башка чакта мәктәпкә берәрсе тәм-том алып килсә, Җәмил, миңа да бир әле, дип үзе беренче аптыратырга тотына иде. Бирмәсәләр, кызларның чәчләреннән тарта, малайларның кулына ябыша, класс, коридор буйлап куып йөри. Андый чакта, парта өсте яки идән бу, дип карап тормый, иң кыска юлны сайлап чаба-чаба мәхшәр куптара иде. Ә бүген ул үзе конфет алып килде. Кызлар сорап авыз ачуга — гомер булмаган хәл:

— Миннән булсын яхшылык, мәгез! — диде дә һәммәсенә өләшеп чыкты.

Кайдан килгән юмартлык икән бу, дип уйларга да өлгермәделәр, күчтәнәчне авызына кабучылар төкеренә дә башлады. Җәмил исә әй шаркылдый, әй шаркылдый. Әмир татып карагач кына белде: конфетын юри борычка манып алып килгән икән иптәше! Чыдамады:

— Җәмил, син менә үзең дустан күпне өмет итәсең, — диде. — Ә үзең бер дә яхшылык күрсәтергә ашыкмыйсың.

— Мин сиңа икенче кесәдән алып бирергә җыенган идем,— диде Җәмил көлүеннән туктап.— Ашыгычлык аркасында оныткандмын. Гафу ит инде!

— Кара аны, моннан соң миңа үпкәлисе булма.

— Телисеңме, сагыз бирәм үзеңә?

— Сагыз чәйнәргә мин кызлар түгел.

— Алайса, тәгәрмәчемне биреп торам,— диде Җәмил, портфелендә актарынып.— Мә, малайларга күрсәтми генә парта буйлап йөртеп кара. Калдырган эзләрен генә күр әле син аның!

— Партаның буявын боза уенчыгың,— диде Әмир төксе генә.

Ул арада дәрес башланды. Җәмилгә «сәгатен» кире портфеленә тыгып куярга туры килде.

Иптәшләрен көлкегә калдыруны уйлап озак баш ватканлыктан, ул дәрескә әзерлексезрәк килгән иде. Өйгә бирелгән язма эшне аннан-моннан гына эшләве, шигырьне дә бик начар ятлавы ачыкланды. Ярый әле физкультурадан өйгә эш бирмиләр. Менә шул соңгы дәрестә күрсәтәчәк тә инде ул үзен.

Дөрес, Җәмил классташлары арасында иң көчлесе дә, иң чыныкканы да түгел. Колгага Гәрәй биегрәк үрмәли, озынлыкка Әмир ераккарак сикерә.

Былтыр алар Сабан туенда да ярышка катнашты. Беренчелекне ала алмадылар үзләре, шулай да мәйданнан кулъяулыгы әләктереп, май ягылган кабартмадай, елтырап килеп чыктылар. Аларны узу кая инде ул, бүтәнчә төп башына утыртса гына...

Бүген Җәмил колгага әйбәт үрмәләрлек итеп әзерләнеп килде. Тәнәфестә барысы да мәктәп стадионына чыгып йөгергәч, ул аулакта портфелендәге сабынлы су тутырылган полиэтилен капчыкны костюм кесәсенә күчерде.

Көн кояшлы иде. Яшел чирәмгә тезелешеп утырган малайлар ун метрлы шома колгага карап киңәшергә кереште:

— Ай-яй озын, моның башына менеп җитә алмам, ахры,— диде Гәрәй.

— Чалбарны салсак, авырттырырмы икән ул? — дип сорады аңардан Әмир.

— Авырттыру нәрсә ул? — диде Гәрәй.— Чыдыйсың инде аны. Менә кулың шуа башласа, начар.

Җәмил аларны мыштым гына тыңлап утырды. Нигә артыгын дулкынланырга? Барыбер колга башына менеп җитү язмаган аңа. Сабын суы гына кесәсеннән агып чыгып тоттырмасын аны, калганына бик исе китми!

Чиреккә билге чыгарыр вакыт җиткәнлектән, шулай да тырышырга булды ул. Бүтәннәр шикелле, кулларын, аякларын төкерекләде. Исемлектә алда торганга, беренче булып колгага килеп ябышты.

— Костюмыңны сал! — дип кычкырды укытучы.— Җиңелрәк булыр.

— Колга алай тәнемне авырттырачак.

Ул, елан кебек буыннарын бер сузып, бер җыеп, өскә үрмәләде. Өч-дүрт колач менгәч үк туктап ял итте. Аннары тагын кузгалып китте. Куллары югарыга сузыла, гәүдәсе аска тарта. Шундый авыр гәүдәсе, гер асканнармыни! Малайлар җирдән куәт өстәп тора:

— Кулыңны төкерекләә!

— Колганы ботларың белән ныграк коч!

— Җитте инде, җитте, төш хәзер. Я орбитадан ычкынырсың!

— Хи-хи-хи!...

Көлегез, көл, борын салындырасыгыз алда әле, дип уйлый Җәмил. Шаркылдаучыларга Әмир кушылмый, тик аның тавышы көч өстәүчеләрнеке арасында да ишетелми. Анты да тукран тәүбәсе генә, ахры. Ә Җәмил абзагыз барыбер бирешмәячәк. Менәчә-ә-әк...

Уф! Ул, кире аска шууын сизеп, ботлары белән колганы ныграк кочты. Яртысын узды микән әле? Узгандыр. Тик тагын бераз үрмәлисе иде. Нигә бу кадәр кага икән йөрәге? Дөп-дөп, дөп-дөп. Беләге талды тагын. Костюмын салып атса, шактый җиңеләер иде дә, нияте үтәлмәячәк алай. Бераз өскәрәк күтәрелмичә кесәсенә кулны тыгу да ярамас. Егерме-утыз күз аңа төбәлгән, шундук күреп алырлар.

Җәмил тагын кызу-кызу кулларын, аякларын хәрәкәтләндерде — янә ике колач чамасы өскә үрмәләде. Колга башына инде ерак калмады, ләкин хәзер терсәк буе күтәрелү дә коточкыч кыен иде. Дәрманы тәмам төкәнде. Җаны чыкканчы аска шуа башларга кирәк. Маңгае, култык аслары тиргә күмелде, иптәшләре исә:

— Борылып конфетыңны капсаң, хәл керер иде инде.

— Җәмил, әллә эчәргә су менгереп бирикме? — дип үртәп маташалар. Соңгысын Әмир кычкырды бугай.

Каударланып онына язган лабаса, ярый әле «су» дип исенә төшерделәр. Җәмил ботлары белән колганы ныграк кочты да уң кулын костюм кесәсенә — полиэтилен капчык эченә тыкты һәм аны, җирдәгеләргә сиздермәскә тырышып, сак кына кире чыгарды да юеш учы белән колганы сыйпап-сыйпап алды. Ул шушы серле хәрәкәтен аска шуа-шуа биш-алты тапкыр кабатлады, калган дүрт-биш метр араны гына таш кебек атылып төште.

Колгага шундук Әмир барып ябышты. Җәмил аны кызганып та куйды. Башта Гәрәй үрмәли башлар, дип уйлаган иде ул. Теге сабынлаган турыга менеп җиткәч нишләр инде ул? Дөрес, Җәмилгә бик ук сабынлы тоелмады әзерләгән суы. Әллә сабыны төпкә утырган шунда?

Әмир исә шактый җитез үрмәли иде. Колганың теге хәтәр җирен дә ансат кына узып китте түгелме? Әллә башына ук менеп җитте инде?

Җәмил таң калып иптәшен күзәтте. Әмир җайлы гына шуып төште дә, мыскылдаган хәлдә иптәшләре янына килеп, җиргә тәгәрәде.

— Менә, малайлар, колга башына менеп җиткәч, сезгә карый-карый эчәргә кызыккан идем, суым әллә ничек болганчыкланган. Карагыз әле,— диде ул костюм кесәсеннән полиэтилен чыгарып.

Малайлар шундук аның тирәсенә елышты.

— Сабынлы ич ул!

Бу сүзләрне ишетүгә, Җәмил ирексездән кесәсенә тыгылды. Аңа төбәлеп торган Әмир:

— Әллә син дә су әзерләгән идеңме? — дип эндәште. Аннары иптәшенең җавап бирүен дә көтмәстән, Җәмилнең кесәсенә үрелде. — Кара, синеке саф чишмә суы лабаса. Әллә безнең капчыклар алышынганмы?

Җәмил комачтай кызарып чыкты. Ул хәзер барын да аңлап алды. Тик кайчан өлгергән Әмир моны эшләргә? Шулай уйласа да, гаебен танырга да, серне ачарга да теләмәде. Бары:

— Юк, минем үз суым ул,— диде.— Миннән соң үрмәләүчеләргә җиңелрәк килсен дип, колганы юешләтергә алган идем.

— Ыш-ш-шыпырт! — диде эшне аңлап бетермәгән малайлар.— Укытучы сизеп алмасын. Колга кипкәнче без дә менеп төшик әле.

— Җәмилгә рәхмәт әйтергә онытмагыз берүк! — диде Әмир җитди кыяфәттә.— Барыбыз өчен дә тырышты ул.

— Булдыргансың, яшьти.

— Колга башына менеп җитсәм, мин сине буш итмәм!

Әмма малайларның бөтенесенә колга башына җитү тәтемәде. Әллә беләкләре сыеграк, әллә ихтыяр көчләре йомшаграк булып чыкты — кем белгән. Акланулары исә бер дә харап иде: алар үрмәләгәндә колганың Җәмил юешләгән җире кибеп беткән, шуңа шомалыгы арткан булган, имеш!

Әмир исә шаяруын дәвам итте. Стадионнан кайткач, гел Динә тирәсендә бөтерелде.

— Бүген ата-аналар җыелышы була ич инде.

Санитар журналын күрсәт әле, кемнәрне әрләтергә җыенасың икән? — дип аптыратты. Журналны кулына төшергәч, Җәмилгә күз кысып, кычкырды:

— Ур-ра! Монда безнең дүрт тә биш кенә икән ич!!

Ул, шатлыгын белдереп, журналны түшәмгә чөя башлады.

— Син нишлисең, яле монда китер тиз генә! — дип кычкырды Динә таләпчән төстә.

Әмир исә чөя дә тотып ала, чөя дә тотып ала журналны. Ахырда журнал стена белән класс тактасы арасындагы ярыкка туры килеп төште югалды. Барысы да «аһ» итте. Чөнки хәзер тактаны кубармыйча журналны кулга төшерү һич тә мөмкин түгел иде.

Җәмил йөгереп килде дә Әмиргә ябышып:

— Син сүзеңдә тора алмаучы тукран! — диде.

— Тәүбә, диген. Миңа түгел, тактага ябыш син әнә. Динәгә журналын алыш!

— Ә вәгъдәң? Нинди вәгъдә бирүеңне оныттыңмыни?

— Кешегә зыян китермәү шарты белән ант итүемне хәтерлим мин. Шартны бозып, үзең вәгъдәне юкка чыгардың ич.

— Юк, син боздың!

Иптәшләре, аларның ни өчен болай якалашуын аңлый алмый, араларына төште һәм колакларына чалынган сүзне кумәкләп кабатлый башлады:

— Тукран тәүбәсе!

— Тук-ран тәү-бә-се!!

Җәмил ике учы белән колакларын каплады.

Йөрәген ярсыта торган сүзләр исә һаман яңгырый бирә, аны тәнәфес бетүен белгерткән кыңгырау чыңлавы да баса алмый иде.

ИЛДАР

Илдар өчен бик күңелсез башланды яңа уку елы. Ни өчен икәнен анык кына ул үзе дә әйтә алмый.

Отряд советына беренче итеп Динәне сайладылар. Әллә шуңа микән? Аннары түбән оч Зыяны, шефка алырга ярата торган Зәйнәпне. Хәер, Илдарның кәефен җибәргән нәрсә бер ул гына түгел икән әле. Үзе белгәннән бирле Тәкрарлек болынында бергә тәгәрәп үскән күршесе Җәмилне дә яшел патруль иттеләр бит. Менә бусы искитмәле инде. Әллә Илдарны күзәтергә кушулары микән? Алай дисәң, аның Илдардан уздырган җире юк: укулары бер чама, тупны да бергә тибәләр, такмакны да бергә чыгаралар. Көчләре дә тигез, кирелекләре дә... Нәрсә маташтырулары икән бу? Эчне кызыксыну кытыклаганда ничек түзәргә кирәк? Кайда юкка чыкты икән соң инде бу Җәмил?

Илдар әзли-әзли аптырап бетте күршесен. Арыпталып бүрәнә өстенә килеп утырганда гына капка шыгырдаган тавыш ишетелде. Юк, Җәмилләрнеке түгел, үзләренеке икән. Кем икән дисә — Динә.

— Нишләп йөрисең бездә?

— Болай гына.

— Ничек инде болай гына?

— Йомыш белән.

Илдар аны башыннан аягына кадәр күздән кичерде. Йомыш, имеш! Аларның нинди йомыш белән

йөрүләрен яхшы белә ул. Былтыр да эти-әнисен ничә тапкыр мәктәпкә чакырдылар. Теңкәләренә тиделәр.

— Я, әйт инде, нигә килдең? Курыкма, дөресен әйт.

— Эш белән,— диде Динә көлемсерәп.

— Авыз ерган булып маташма, әйт диләр ич сиңа. Югыйсә... синдәй чәчбиләрне генә тыңлата беләм мин!

— Нишләтерсең?

— Ишеткәнең юкмыни? Кара сыер кабыргасын мин бер үзем кимердем, байтак тәти кызыйларның борыннарын җимердем!

— Фи, батыр! Кызларга көче җитә, имеш.

— Син Җәмилгә авызыңны ыйшайт, яме. Ә минем талканым коры.

— Җәмил миңа нәрсәгә? Миңа синең белән сөйләшү кызык.

— Ярар, синең белән сайрашып торырга мин кызлар түгел. Сыпырт моннан. Актык килүең булсын, кара аны,— дип Илдар җирдән юеш балчык алды да Динәнең портфеленә ыргытты.— Урам пычрак безнең, тагын килсәң, муеннан батуың бар!

Аннары Динәнең ник килүен белер өчен өйләренә йөгерде. Шиге дөрес булган икән, кызый класс җитәкчесеннән язу китергән. Дәрескә ручкасыз йөргән өчен, әй, эләкте дә соң атасыннан!

Бар гауга Динә аркасында гына чыкты, дип Илдар урамга ашыкты. Тагын да шәпләп кундырырга иде үзенә, бәхете, китеп өлгергән икән. Инде нәрсәдән юаныч табарга соң? Һәй, капкаларыннан Җәмил башын тыккан түгелме соң?

— Әй син, пионер күзәтчесе, нәрсә борыныңны чөйдең?

Җәмил, Илдарның эндәшүенә исе китмәгән төсле, черт иттереп җиргә төкерде. Бу да кылана инде. Илдар, аның җавап бирмәвенә үртәлеп, тиз генә хәтеренә килгән беренче такмакны ярып салды:

— Җәмил төшкән буага битен-кулын юарга, менәлмәгән, егылган, күзенә яшь җыелган. Шәпме, ә-лә-лә! Хурлык, ә-лә-лә!

Җәмил сүлпән генә:

— Алай икән,— диде.

— Алай икән, кураең калай икән, каләмең көмеш икән, борының юеш икән!

— Иске такмак,— диде Җәмил, борынын җыерып.

— Чыксам өйдән, Җәмил килгән, корсагы кибән, борынын чөйгән.

— Я, я, кемнең корсагы кибән? — дип малай Илдарга якынлашты.

Ә Илдарга шул гына кирәк тә иде. Җәлт иптәшенең якасыннан! Китте алыш, әүмәкләш...

Пыр килеп сугышып ятканда, аларны әллә кайдан килеп чыккан Зыя аерды.

— Сез нәрсә, ике дус?— диде ул исе китеп. — Менә сезгә күршеләр!

— Ә нәрсә ул мине үрти? —дип акланды Җәмил.

— Ярар, синең янга килешем иде әле минем, әйде өегезгә керикче,— дип туктатты аны Зыя.— Үзең патруль, үзең сугышып йөрисең. Алгебрадан эшләдеңме соң әле?

— Һи-һи, шефы килгән икән Җәмилнең,— диде

Илдар.— Шеф баш, Җәмил муен, Җәмилгә уен, шефка кыен. Һи-һи, шуңа акыл өйрәттерәмме соң? Әй, шеф, кил әле монда, татар самбосы күрсәтим үзеңә!

Шулчак алар янына классташлары Зәйнәп килеп басты. Илдар аңа таба борылды да эре генә эндәште:

— Безнең урамда ни калган бу кызыйга?

— Мин сиңа дәрес әзерләшергә килдем.

Илдар, аны танымаган кебек, кулын кашы өстенә куеп карады да, ишегалларына ук сыман атылып кереп, капкаларын эчтән бикләп куйды.

— Урамда гына әзерлә инде син. Җәмилләр дә бар әнә иптәшкә, бергә-бергә рәхәтләнегез. Шефка ал җебегәннәрне. Ә миңа үз башым да җитә. Хуш! Тагын күзгә кадалып маташсаң, кара аны. Бар, бар, тай моннан, алдыңнан артың ыспай!

Отряд сборында иптәшләре алдына чыгып баскач: «Нигә бу кадәр кыланалар соң Зәйнәпләр? — дип уйлады Илдар.— Мәктәпкә килеп әләкләргә дә өлгергәннәр. Җитмәсә, стена газетасына да рәсемен ясап куйганнар. Ничек кенә диген әле. Алагаем зур кантар белән Динәгә кизәндереп. Болай тәфсилләп Җәмил җиткергәндер инде. Йөри шунда кызларга сатылып...»

— Илдар үзен пионерларча тотмый,— дип сөйли иде отряд советы председателе Фәйрүзә, сүз алып.— Иптәшләрен санламый, Динәне хәтта балчык атып куып җибәргән.

— Дәрес әзерләшергә барган Зәйнәпне дә өйләренә кертмәгән,— диде малайларның берсе.— Эт ачуын торнадан ала.

— Болай санламый йөргәч, әйдәгез без дә аңа үзе шикелле булыйк, төп башына утырсын әле,—диде звено вожатые Зыя. — Моннан соң аның белән бергә уйнамыйк та, сөйләшмик тә!

Отряд бу тәкъдимне хуплап кул чапты. Күршесе Җәмил дә якламады Илдарны. Үзенә болай ябырылырлар дип көтмәгән иде. Шулай да гафу үтенергә җыенмады. Күңеленә шом төшсә дә, гарьлек җиңде бугай.

Отряд сборы Илдарга сынау вакыты билгеләде.

Төштән соң бишенчеләр шау-гөр килеп урманга китте. Дару үләннәре җыярга, бергәләп ял итәргә, уйнарга. Илдарны гына чакыручы булмады. Гел бергә чалбар туздырып йөргән Җәмил, Мөдәррисләр дә иптәшкә калмады бит. Ярар, уйнарга бүтән класс малайлары да бетмәгән әле, дисә, алар да урманга киткән булып чыкты.

Урам буш. Чирмешән буенда да җан әсәре күренми. Илдар, кая барып бәрелергә белми эче пошып йөри-йөри, көчкә кич җиткерде. Бер заман чыр-чу килеп, төянеп-күтәренеп урмандагылар кайтты. Илдар аларны кырыйдан, мәктәп рәшәткәсе арасыннан карап торды. Әнә Зыя белән Җәмил мыдыр-мыдыр сөйләшеп бара. Зыя да Илдарлар урамына борылды. Тагын бергә дәрес әзерләргәдер инде. Әллә Илдарның күзенә төтен җибәрүләреме? Җәмиле дә куып биздерми бит шуны.

— Әй, Зыя, күпме дару үләне җыйдыгыз? — дип сорады Илдар малайларга ияреп. Әмма малайлар аңа борылып та карамады.

— Мүкләк Җәмил йөгәнсез йөри алмый, шеф кирәк булган,— дип кычкырды Илдар, ачуы чы-

гып. — Иптәше — Зыя, Җәмилне тыя, тыңламаса, суя.

Ә малайлар Җәмилләргә кайтып җиттеләр дә нәкъ Илдарның борын төбендә генә капканы шартлатып бикләп куйдылар. Менә сиңа күрше, менә сиңа дус. Кыланмышлары кырга сыймый. Үчекләүгә дә, араларына чөй кагуга да бирелмәгән булалар, авызларына су капканнар.

«Бераздан бәлки үзләре чакырыр әле», дип уйлады Илдар. Әмма капка ачылмады. Торып-торып та файда чыкмагач, үз капка төпләренә барып утырды. Аларсыз да яши ала ич ул, тик чүбек чәйнәп ятсыннар. Тукта, аның янына да берәр иптәше генә килсен әле, ул да Җәмилнең хәленә кермәс — бусагага аягын да бастырмас!

Озакламый урамда аръяк малае Сабирҗан күренде.

— Әй, ахири, кил әле монда-а-а!

Алтынчыда укый иде бу малай. Тик ул да Илдарның чакыруына ашыгып төшмәде. Яртылаш борылды да:

— Юньле булсаң, класташларың иптәш итәр иде сине, — диде һәм аргы урамга таба атлады.

Нәрсә болар барысы да каныга соң әле аңарга? Тапканнар дошман.

Илдар аннан соң да байтак вакыт капка төбендә нәрсәдер өмет итеп утырды. Менә кояш баеды. Әкренләп эңгер төште, салкынайтып, чиркандырып җибәрде. Ә Илдар һаман берүзе. Моңсу да, күңелсез дә иде аңа...

ШАЯРУ

Сугыш беткән елны мәктәбебезгә ир укытучылар кайта башлады. Шуларның берсе Рәҗәп абый безне немец теленнән укытырга керешге. Әүвәлге укытучыбыз кебек татарча сөйләшми, дәресне немецча гына алып бара. «Гутен таг!» дип исәнләшә, «Ауф видер зин!» дип саубуллаша. Без дә аңа:

— Гутен таг! Ауф видер зин! — дип җавап бирәбез. Кызык.

Менә шул «Гутентаг» быел безнең класс җитәкчебез булды. Ир башы белән бер кирәкмәгәнгә дә ваклана башлады тагын. Әле өй хәлләрен сораша, әле дәфтәрләрне карый. Кырыс, таләпчән. Шулай да, фронтта батырлык күрсәтә алмаган, ахры. Орден, медаль такканы күренми. Әллә анда да юкбар эшләр генә үтәп йөрде микән? Немец телен белсәм, мин аның урынында разведкада гына йөргән булыр идем. Үсеп җитешә алмый калдым. Югыйсә туздыра идем мин ул дошманнарны. Барыбер укыйсым килми, нигә фашистларны гына кыйнап йөрмәскә?

Менә бүген дә бармадым әле мәктәпкә. Башка авылда укуның рәхәте дә шунда инде, укытучы көн дә өйгә килеп йөри алмый. Мәктәпкә дип чыгып китәсең дә рәхәтләнәсең берәр аулак җирдә уйнап.

Җәмилгә әйтмәдем. Югыйсә син ияртәсең, дип әле әбисе, әле укытучылар бәйләнә. Йөрсен әле укып! Үскәч барыбер ат көтәчәкбез ич инде, сөйләшенгән. Әнкәйгә сиздермичә генә бөгәлҗәне әләктердем дә күпер төбенә сыздым.

Бөгәлҗә дигәнем үзебез ясый торган балык то-

ту коралы инде. Ике пеше таякны аркылы-торкылы куясың да, дугаландырып бөгеп, очларын баш яулыгы кадәр генә киндернең дүрт чатына беркетәсең. Киндер кырыйларын өскә кайтарып тарттыргач, суны иләк шикелле үткәрә торган «җәтмә» барлыкка килә. Уртасына ипи катысы яки бәрәңге — жим бәйләп куйганнан соң, бөгәлҗә әзер. Аны елга төбенә төшерәсең дә җимгә балык җыелуын көтәсең. Аннары бөгәлҗәне сак кына судан чыгара башлыйсың. Зурлары, чаялары качып өлгерә, эмма балыкның хәтсезе сөзелеп кала. Хәер, эш балыкта гынамыни? Кәҗәсе түгел, мәзәге кыйммәт ич аның!

Күпер төбендә су тирән, монда балыкның оясы. Тик башта миңа берни эләкмәде. Әле суы да салкын иде, ярга чыгып җылынып утырдым. Аннары яңадан яр астына төштем. Балакларымны сызганып, елга уртасына кереп бастым. Әмма тагын уңмадым. Менә бит, куркытучы кеше де юк, ник бер дә керми икән балык? Әһә, нәрсәдер бар, тәпиләремне дә кытыклыйлар инде!

— Һайт!

— Ә-ә?

— Әмир энекәш, балык керәме?

Харап булдым, күпердән башын сузып кычкыручы Рәҗәп абый икән ич! Чалбар төпләрем юешләнеп китте, сискәнүдән чүгеп җибәргәнмен ләбаса. Чыгара башлаган балыкларым да киндер читеннән чулт-чулт суга сикерделәр.

— Качтылар,— дидем мин ярга чыга-чыга.

— Һай, мин сине балык тотарга оста бу, дип уйлаган идем тагын.

Ник кенә шушы күпер төбенә төштем икән?

Юл өсте икәнлегеп дә белдем үзе. Балык оясы дип алдандым шул. Хәер, Рәҗәп абыйның мине башка җирдән дә тапканы бар инде.

Беркөнне без Мөдәррис белән, күз авырта дип хәйләләп, укудан калган идек. Юкәдән насос ясап маташканда Рәҗәп абый килүе күренде. Җәлт печәнлеккә без! Укытучы өйгә керде, анда беркем дә булмагач, кире ишегалдына чыкты. Китми дә китми генә. Өй биксез булганга шикләнде, ахры. Эзләнә башлады. Келәткә керде, аннары лапасны тикшерде.

— Ә-ә-ә, менә кайда икән сез!

Тотылдык. Шул Мөдәррис, былтырдан калган миләшкә үрелеп, әллә кайдан ишетелерлек итеп шыштырдады.

— Әйдә мәктәпкә киттек, дуслар,— диде Рәҗәп абый.

— Укулар бетте ич инде.

— Мин сезгә икенчесен үзем укытырмын.

Түбән очтан узып барганда безне кизләүгә кер чайкарга төшкән әнкәй күреп алды.

— Әмир, кая барасың?— дип кычкырды ул.

— Мәктәпкә.

— Мунча ягып йөрим ләбаса, төштән соң нинди уку ул тагын? Чирле балага нинди мәктәп ул, яле хәзер үк кире борыл!

— Менә ич,— дидем мин Рәҗәп абыйга ымлап.

Әнкәй шунда гына укытучыбызны танып алды. Яклап каласы урында орыша да башлады:

— Ах, уңмаган, әле син алдалап калган идең мени укудан?!.

Китте, китте, тетә мине әнкәй. Рәҗәп абый исә

алып китүен белде. Әллә нинди үҗәт укытучы булып чыкты ул, әнкәй кыздырганда да безне кызганмады.

Менә бүген дә барабыз. Бер кулымда — киндер букчам, икенчесендә — бөгәлҗәм. Рәҗәп абый үзе велосипедка атланган. Тәгәрмәче тишелсә иде ичмаса шуның. Мине әйдәп барган өчен генә барыбер медаль бирмиләр ич инде аңа, сугышта алалар аны! Һич югы, бөгәлҗәмне дә калдыртмады. Ник болай артымнан йөри икән инде ул? Класста миннән башка да егерме биш кеше ич әле. Дөрес, Рәҗәп абый аларны да игътибарсыз калдырмый, әмма миңа аеруча бәйләнә сыман. Әле былтыр гына мине чаңгы ярышына барыр өчен мәктәп командасына да керттерде. Анда шәп йөгерүем өчен чаңгы бүләк иттерде. Үзенчә, күңелне үстерергә тырышуы булгандыр бу. Тау шуарга әйбәт булды үзе. Әмма шуннан соң... ул бит миңа: спортчыга фәлән ярамый, төгән ярамый, килешми, дип әйтә-әйтә күземне дә ачтырмый башлады! Чаңгы бирдерттем, шуңа күрә бәйләнергә хакым бар, дип уйлый микән әллә? Кем соң ул миңа шул хәтле? Ни туган, ни дус түгел. Ярар, бер кызык итәрмен әле моның өчен үзен дә. Башка авылга, җитмәсә, бөтен кеше күз алдында мәктәпкә бөгәлҗә күтәртеп баруын, мәсхәрә итүен онытмам...

Иртәгесен үк бик әйбәт шаярттым мин аны.

Мичкә тәгәрәткән бәрәңге яратам мин. Күмер өстендә, я булмаса, кызурак ягылган мичтә пешсә, бәрәңгенең кабыгы кызарып, көебрәк тә китә. Әнә шул көйгән исләрен чыгарып, җир алмасының чикмәнен салдырып маташу үзе үк күңелле миңа. Аны

шул кадәр яратам, кай көннәрдә мәктәпкә дә алып бара идем. Кесәгә салганда кулны пешерерлек кайнар була ул, җанашым. Мәктәпкә килеп җиткәнче үзен искә төшереп, йөрәкне җылытып тора.

Бу юлы да шулай булды. Әмма тәнәфестә ул онытылды. Пыр килеп шаярыша башладык. Коридордан ишегалдына, аннан урамга атылдык. Җәмилнең өстенә атланган башка авыл малаена чебешкә ташланган тилгәндәй ыргылдым. Килеп тә җиттем, алып та аттым тегене! Шунда мине кайсыдыр аяк чалып екты. Тагын кемнәрдер ябырылды. Әй авыр, иң аста калганмын икән. Кайсы ялагае яклады икән теге ихахайны? Ычкыныйм гына, эзенә төшәрмен.

Кыңгырау шалтырады. Барысы да дәррәү классларга йөгереште. Өстемне каккалап керсәм, Рәҗәп абый дәресне башларга да өлгергән икән. Ул миңа таба әйләнеп:

— Сиңа тәнәфес җитмәдемени? — диде.

— Кыңгырау ишетелмәде. Урамга чыккан идек.

— Колагың төзәлмәсме, такта янына килеп бас! — Аннары класска борылып дәвам итте: — Өйгә бирелгән эшләрне тикшерәбез.

Минем өй эшем аннан-моннан гына эшләнгән, күрсәтеп торасы да юк. Кулларымны кесәмә тыккан идем — боламык! Хараплар гына булганмын.

Менә Рәҗәп абый өйгә бирелгән эшләрне карап чыкты. Аннары миңа таба борылды:

— Әмир, яле син дә дәфтәреңне китер әле?

Партага барып букчамны актардым. Аннан нәрсәдер алып кесәмә яшергәндәй кыландым. Аннары гаепле кеше төсле:

— Дәфтәрем өйдә калган икән,— дип акландым.

— Кесәгә сала торганы онытылмаган. Нәрсә яшердең анда?

Берни дәшмәдем. Беләм инде, аның минем кесәдән берничә тапкыр тәмәке алганы бар. Бу юлы да карамый калмаячак.

— Монда кил әле!

Өстәл янына барып бастым.

— Чыгар кесәңдәгене!

Мин, киресенчә, кесәмне кулым белән каплагандай итеп тоттым.

— Әмир, ишетәсеңме?

Кулымны кесәмә үк тыктым да ләм-мим әйтми тора бирәм.

— Чыгар кулыңны!

Рәҗәп абый минем шулкадәр кире булуыма исе китеп, ниһаять, кесәмә үзе сузылды. Кулын кыю гына батырды да, электр тогына орынгандай, капылт кире тартып алды. Бармаклары кесәмдә изелеп беткән бәрәңгегә буялган, йөзе аптыраашта, ирен-нәре:

— Әй, бәрәңге икән,— дип пышылдады.

Бөтен класс пырхылдап көлеп җибәрде. Үзем исә, дөньядагы иң гөнаһсыз бәндә кебек, башымны аска идем.

Җәмит минем өчен укытучылар бүлмәсендә төгәлләнде.

— Син беләсеңме, Әмир,— диде директор,—Рәҗәп абыең запастагы офицер бит. Дан ордены кавалеры. Сезне саклар өчен сугышып әллә ничә мәртәбә яраланган. Үз балалары, бөтен гаиләсе дошман тылында калып һәлак булган. Хәзер ул барлык

көчен, сәләтен, йөрәк җылысын сезне тәрбияләргә бирә. Әсин аш белән атканга таш белән!

Мин мондый ук хәбәрне көтмәгән идем. Менә сиңа җебегән сугышчы, сәер укытучы! Хәзер оялмыйча ничек күзенә күреним икән мин аның?

ФОТОАППАРАТ

Күптән инде Динәнең күзенә чалынасы килеп йөри идем. Яхшы яктан, булдыклы малай булып. Шуңа күрә җилкәмә фотоаппарт асып баруыма сөенеп бетә алмадым. Йөрәгем канат чыгарган кош баласыныкыдай дәртле тибә. Өстәвенә, көмеш чык бөртекләре җемелдәшкән чирәмле юлдан атлаганда Гәрәйләр:

— Яшьти, бераз мин дә асып барыйм инде? — дип ялына.

Тик мин аларга:

— Сезгә ышанып тоттырсаң, кәкре каен терәп калырсың! — дип бик тәкәббер җавап бирәм.

Ә елга башына килеп җитеп, тирә-юньне черт тә черт кәртечкегә төшерәчәгем алдан ук күңелне кытыклый. Күз алдына китерегез: Җәмил, Мөдәррисләр бөтен әртилләре белән кызыгып, көнләшеп сиңа карап торганда ашыкмыйча гына өчаякны утыртып куясың, фотоаппаратны аңа җайлап беркетәсең. Аннары, менә мин кем дигәндәй эреләнеп, теге-бу җирләрен боргалый, аппаратны кора башлыйсың. Малайлар сабырсызланып «Төшерәм!» диюеңне көтәчәк. Җәмил, билгеле инде, дуслыкка аркаланып, фотога беренче эләгүне өметләнә. Алар янында,

һич тә сер бирмәскә тырышып, бераз көлемсерәгән Динә басып торачак. Шәп бит, ә?

Динә дигәннән, аның фотоаппараты ич әле бу. Кичә география дәресендә укытучыбыз Рәйхана апа:

— Иртәгә Чирмешән башланган җиргә экскурсиягә барабыз. Шул тирәләрне фоторәсемгә төшереп кайтасы иде. Кайсыгыз булдыра алыр икән бу эшне? — дигән иде.

Шау-шуыбыз су сибелгән тузандай басылды. Кем гайрәт күрсәтсен? Мәктәптә кышын фототүгәрәк эшләсә дә, анда безнең класстан берәү дә йөрмәде. Аппаратың булмагач, ни файда? Әнә Динәгә агроном әтисе бүләк иткән дә бит, кадерен беләмени ул аның? Тотып та карамый!

Кичә барыбер телгә алдык әле үзен.

— Динә төшерсен, аның фотоаппараты да бар,— диде Гәрәй.

— Күрсәтсен әле һөнәрен! — дип куәтләде аны Җәмил.

Пырхылдадым. «Һөнәрен» имеш, нәрсә төшерсә дә, күләгә генә чыгара ич ул. Шулай да авызны озак ермадым. Мөдәррис я Җәмил булса, үртәп җаннарына тияр идем дә, Динәгә тел озайтасым килми. Кыз кеше ич ул.

— Шаулашмыйча гына, балалар! — диде Рәйхана апа. Аннары Динәгә борылып эндәште: — Я, ничек соң, Динә, булышасыңмы класска?

— Мин... мин ни... төшерә белмим шул әле.

Башка вакытта чатнап торган тавышы көчкә ишетелә. Их, фотоаппаратым булсамы! Әле болай да бераз маташтырам. Күрше малаеның «һәвәс-

кәр»е белән хыйт килеп, йорттыр, коедыр — юлда очраган бер нәрсәне кәртечкегә төшереп йөргән идек. Фотоаппаратына күрә рәсемнәре дә ярыйсы чыкты. Ә бу Динәнең «Һәвәскәр» генә түгел, гармунныкы кебек күреге дә, өчаягы да булган менә дигән «Фотокор!» Һәр җире ялтыр-йолтыр килеп тора. Май чүлмәгенең тышыннан билгеле шул!

— Бәлки арагызда остараклар бардыр? Динә фотоаппаратын биреп торыр иде,— дип эндәште безгә Рәйхана апа.

— Бирәм,— диде Динә җиңел сулап.

Без яңадан тынып калдык. Берәүнең дә бу эшне үз өстенә алып оятка каласы килми. Минем генә эчем кымырҗый башлады. Дөрес, минем «Фотокор» белән эш иткәнем юк. Тик... фотоаппарат тотып карамаган малай түгел ич инде мин. Әгәр эшне ялт иттереп башкарып чыксам, даны ни тора! Соңыннан, мине дә өйрәт әле, дип Динә дә ялынып йөрер иде.

Әллә нигә танытасым килә үземне шул кызыйга. Миңа аның алмадай ал битләрен чокырайтып, шомырт кара күзләрен очкынландырып торуы ошый. Шефка алып дәрес әзерләшергә йөрүенә гарьләнсәм дә, соңгы вакытларда менә шул алма бит, шомырт күзләре хакына түзеп киләм. Чәчләрен алтын сары тасма белән үрә, ул тасмаларның шаян койрыклары, кояш нуры сыман, Динәнең ак муенын иркәләп уйный. Менә нинди кыз бит ул! Дәрәҗәмне җитәрлек күтәргәч, дуслык хакына үзен кәртечке төшерергә дә өйрәтми ярамас.

Шундый уйлар башыма килде дә тәвәккәлләргә булдым. Җавап көтеп Рәйхана апага:

— Үзем сынап карыйммы икән? — дидем. Шундук болай мескеннәрчә эндәшүгә генә я ышанып бетмәс дип, батыррак итеп өстәдем: — Элек төшергәнем бар иде.

Хәзер менә фотоаппарат җилкәмдә, шау-гөр килеп чиксез ялан, иген кырлары буйлап атлыйбыз.

— Чирмешән авылыбыздан унбиш чакрымнар ераклыктагы бер басуда нәни генә чишмәдән башлана икән,— диде Динә.

Әмма Җәмилнең уе бөтенләй башкада. Ул малайлар белән чиратлашып өчаягын күтәреп баруга гына риза түгел, тагын:

— Фотоаппаратны да бераз тотып карыйм инде, ә? — дип аптырата башлады.

Динә күз алдында тоттыраммы соң! Киресенчә, мин аны тагын да кадерләбрәк терсәгем белән янтыгыма кысам. Әйбернең ышанычлы кулда икәнен күреп торсын әле хуҗасы!

Юлның яртысын уздык микән, арыта башлады. Рәйхана апага әйттек тә Чирмешәннең таллы яр буена төшеп, ял итәргә туктадык. Якында гына челтерәп чишмә ага иде. Аның суы көмештәй саф, боздай салкын. Тәмле. Кулларны юдык та биштәрләрне актарырга керештек. Рәйхана апа:

— Табын бер булсын әле, барыгыз да ашамлыкларны уртак җәймәгә чыгарып тезегез,— диде.

Ул үзе, үрнәк күрсәтеп, кабарып торган портфеленнән берничә балык консервасы һәм кыярлар чыгарып куйды. Без дә, ут капкандай каударланып, хәзинәдә барын уртаклашырга ашыктык. Билгеле, байлык чамалы — бәрәңге дә ипи, кукәй дә тоз иде.

Шулчак тагын Динәгә үземнең кемлегемне күр-

сәтергә җай чыкты. Калай банкалардагы авыз суларын китереп торган балыкны бармак белән ашамассың ич инде. Ярый әле агач саплы пәкемне дә сәяхәткә алганмын. Талдан әллә ничә кешегә калаклар ясап бирдем. Ә Динәнекен аеруча матур итеп юндым, сабын сырлап, бер җиренә «Д» хәрефен дә уеп яздым. «Ә» дип үз исемемне дә өстәмәкче идем әндә, тартындым. Мөдәррисләр күзне дә ачырмас аннары. Хәер, болай да җиткән иде инде, бүтәннәрнекенә караганда пөхтәрәк ясалган калакны алганда Динә бераз кызарынып та китте бугай.

Тәнгә хәл керде, күңелләр ачылды. Мөдәррис белән Җәмил ул арада сикереп тордылар да су коенырга йөгерделәр. Алар артыннан бүтәннәр дә купты. Мин генә, фотоаппаратка ул-бу булмагае дип, Рәйхана апа янында утырып калдым.

Бераздан яңа дәрт, яңа һәвәслек белән янә дә үҗәтләнебрәк юлыбызны дәвам иттек. Егерме чакрым узганбыздыр инде, ачуым килмәгәе. Көн кичкә авышкач кына елганың тарая, ярлары чүгә баруын сизә башладык. Йөрәкләребез сөенеч белән тибәргә тотынды, күзләребездә якты очкыннар кабынды. Үз-үзебезне тыя алмыйча, кем беренче елга башына барып җитә дип, җан-фәрман йөгерешә башладык. Бу мизгелдә һәрберебез үзен яңа җирләр ачучы кыю сәяхәтче, армас-талмас дәртле илгизәр итеп тойды.

Әмма җилкәмә кадерле йөк — Динәнең күз карасы кебек саклап йөртә торган «Фотокор»ы асылганга, мин инде бу юлы гадәттәгечә онытылып томырыла алмадым. Нигә дисәгез, мин бүген Чирмешән башына алдан килүем белән түгел, ә бөтен-

ләй башкача — елгабызга тереклек бирүче беренче чишмәне, аның тирәсенә тезелешеп утырган классташларымны кәртечкегә төшерүем, шулай итеп, сәяхәтебезне истә калдыруым белән танылырга тиеш идем.

Менә ул кайчаннан бирле хыялларыбызны биләгән Чирмешән башы! Рәйхана апа килеп җиткәнче, без этешә-төртешә елга кадәр елганың башы булган чишмәнең суын татырга да, бер читкәрәк китеп битләрыбызны юарга да өлгердек. Аннары янәшәдәге мүк үскән бүрек сыман түмгәкләргә башны куеп чалкан яттык. Рәхәт, бик рәхәт иде монда буыннарны язып хәл алу.

— Әмир! Кояш байый лабаса, кор тизрәк фотоаппаратны,— дип кычкырды килә-килешкә Рәйхана апа.

Офыкка кичке шәфәкъ кызыллыгы җәелә башлаган иде инде. Юл буе хыялымны дөрләтеп, мине татлы уйлар кочагында эретеп рәхәтләндергән эшкә тотындым. Хәзер, миңа калса, дөньяда фотограф хезмәтеннән дә катлаулырак, мәртәбәлерәк, аннан да әһәмиятлерәк берни юк иде. Шуңа күрә иптәшләремнең түземсез карашларыннан кинәнеп, бигрәк тә Динәнең күзен алмый көтеп утыруыннан ләззәтләнеп, һәр хәрәкәтемнән тәм табып кыймылдадым.

Өчаякны эре генә кыяфәт белән күтәреп ташлыкка китереп урнаштырдым — чишмә әйбәт күренә торган иң шәп урын шунда иде. Аннары фотоаппаратны өчаякка беркеттем дә яман серле бер төс белән көннең шушы вакытына кулай диафрагма зурлыгын, «күзен» ачып тору мизгелен исәпләдем. Шуннан соң фотоаппарат япмасы астына башымны

тыгып, объективны чишмәгә төбәдем. Малайлар таралышып утырганга, байтагы рәсемгә эләкми калачагын күреп:

— Зәки, син Җәмилләр ягына күчеп утыр әле. Гәрәй, син дә! — дип кычкырдым.

Юк, һаман кирәгенчә утырмыйлар. Ачуланып башымны япма астыннан чыгардым да шул хәчтерүшләргә урын күрсәтергә йөгердем. Ул арада кинәт җил чыгып, артымда чырт иткән тавыш ишетелде. Борылып карасам, торна аяклы фотоаппаратны җил бәреп ташлыкка каплаган!

Кире чабып килсәм, ни күрим: бер пыяласы челпәрәмә килгән, объективы чатнаган, күреге купкан! Эчем жуу итеп китте, агарынып-күгәренеп өнсез калдым. Кызлар, малайлар чыр-чу киләп мине урап алдылар.

— Ватылганмы?

— Төшерерлек түгелме? —дип эндәште иптәшләрем.

Мин аптыравымнан айный алмый тордым. Рәйхана апа:

— Я, балалар, борчымагыз әле Әмирне,— дип фотоаппаратны әйләндергәләп карады да башын чайкады. Аннары аны өчаягыннан бушатып алып тартмасына салып куйды һәм берни булмагандай: — Балалар, монда килү гел элекми, тирә-юньгә яхшылабрак күз салыгыз, истә калырлык булсын. Озак мыштырдамый кайту юлына да кузгалырбыз,— диде.

Үзем дә сизмәстән яшертен генә Динәгә күз салдым. Беләм ич инде, энисе: фотоаппаратыңны теләсә кемгә тоттырма, дип гел колагына тукып килә. Хәзер Динә эченә тәмам пошаман төшкәндер. Әмма

ул уйларын йөзенә бер дә чыгармаган иде. Иптәшләре белән тыныч кына нидер сөйләшеп тора. Әйтерсең мин дә, ватылган фотоаппарат та дөньяда юк иде. Мондый битарафлык миндә тагын да ярсулырак, әрнүлерәк тойгылар уятты. Башкаларга аңгы-миңге генә иярдем. Колагым берни ишетми, күзләрем берни күрми. Миемне рәхимсез сораулар телгәли: хәзер Динә күзенә ни йөз белән карармын? Фотоаппарат зыянын ничек түләрмен? Рәйхана апа белән классташларым алдында нәрсә дип акланырмын? Их син, мәми авыз, иштең ишәк чумарын!

Шундый уйларга чумып күпме атлаганмындыр, берзаман Мөдәрриснең:

— «Фотокор» бер сарык бәясе тора икән! — дигән сүзләре колагыма чалынды.

Ул арада безне нindидер атлылар куып җитте. Аларга утыргач, көне буе килгән араны берничә сәгатьтә узып, кичке утлар алынганда авылыбызга кайтып җиттек. Өйләргә таралганда Гәрәй миңа:

— Син кайгырма! Берәр җаен табарбыз әле,— дип пышылдады.

Нәрсә эшли ала инде ул? Күп булса, Мөдәррисләргә ияреп мыскыл итүдә катнашмас. Ә Динәгә җавапны барыбер үземә бирәсе. Озакка сузмый бәхилләтергә кирәк ич аны. Төзәтә алырлык әйбер дә түгел, ичмаса.

Өйгә кергәч әткәй-әнкәйгә «ардым» дидем дә ашамый-эчми урыныма барып аудым. Бераз уфылдап әйләнгәләгәч, талчыгуым үзенекен итте — йоклап киткәнмен.

Ял көне булганга, иртән мине берәү дә уятмады. Күземне ачканда сәгать ун тулып килә иде инде.

Бар ялыныч әткәй-әнкәйгә төшәсе булганлыктан, мин бүген өй эшләрен аеруча тырышып башкардым: утын ярдым, тирес түктем, ишегалдын, капка төпләрен себердем. Шулар белән мавыгып, кичәге кайгым да онытылды. Өйдәгеләр әле хәвефле хәбәрне ишетмәгәннәр, уңганлыгымны мактапмы-мактыйлар. Билгеле, алар шатланып йөргәндә, фотоаппарат турында әйтеп, кояштай балкыган йөзләренә кара болыт күләгәсе төшерәсем килмәде. Шулай тагын бер төн үтте.

Әмма күпме генә тартып-сузып маташсам да, дүшәмбе иртәсендә Динә алдына, башка классташларым алдына барып басу һәм җавап бирүдән кача алмый идем мин. Моны бик яхшы белсәм дә, ул минутларны мөмкин кадәр кичектерергә тырыштым. Теләмичә генә киендем, сүлпән генә урамга чыктым. Ә көне миңа үч итеп дигәндәй матур иде. Чалт аяз.Тик мин дөньяга һаман риза түгел, чырайны сытып бер атлыйм да туктыйм, туктыйм да экскурсиядә кодрәчләнүемне ачынып исемә төшерәм.

Әнә шулай терәлгәләп барганлыктан, класска иң соңгы кеше булып килеп кердем. Дөрес уйлаганмын икән: ишекне ачуга барысы да күзләрен дүрт итеп миңа карады һәм, нидер көткәндәй, тынып калды. Дәрес башланырга ун минут вакыт калган булганга, әллә кире борылыйм микән, дип тә уйлап алдым, тик күзләрем Рәйхана апага, аннары өстәл өстендәге әйберләргә төшкәч, нишләргә белми аптырадым. Әйберләрнең берсе — өченче көн мин ваткан «Фотокор», ә икенчесе — өр-яңа фотоаппарат иде.

Ул арада Гәрәй өстәл янына чыкты да яңа фотоаппаратны алып миңа сузды һәм:

— Әмир, фотографиягә һәвәслегеңне истә тотып, сиңа классыбызда фототүгәрәк оештыруны тапшырабыз. Без бергәләп өр-яңа аппарат алдык менә,— диде.

Мин күзләремә дә, колакларыма да ышанмадым.

— Әйе, әйе,— диде Рәйхана апа.— Бергәлектә бәрәкәт. Аның бәясен иптәшләрең үзара җыеп түләргә булды, ә мин кичә район үзәгенә барып алып кайттым. Шунда Динәнекен дә төзәттердем.

Тамагыма әллә нинди кайнар төер тыгылды, күзләремне челт-челт йомгаладым. Күңелем тулуын иптәшләремә сиздерергә теләмәсәм дә, яңагым буйлап тәгәрәгән тамчыларны мин берничек тә туктата алмадым. Нигә дисәгез, Динәнең йөзендә шат нурлар уйнавын, аның миңа дустанә каравын да күреп калган идем бит мин.

ҮПКӘ

Бүген никтер малайлар урамда чуалмый. Әткәйәнкәй әллә кайчан эшкә киткән. Алар калдырган сөт белән ипине капкаладым да Чирмешән елгасы буена сыпырттым. Монда исә әлегә бер кеше дә юк икән, су өстендә көмеш тәңкәләр генә бии. Чабаклар сикерә тагын. Их, яңа бөгәлҗә ясап тотарга шуларны! Тик барып чыкмый шул ул минем. Бөккәндә я таякларын сындырам, я җәймә чатларын ертып җибәрәм. Ә Мөдәррис...

Аларның өе безнең тәрәзәдән күренми, морҗаларын гына шәйләргә була. Мөдәррисләрнең бирге ягындагы йорт уч төбендәге кебек, анысы — Җә-

миллэр. Бу арада анын белэн эшнэлек тагын суынып тора эле. Шуңа күрэ анын белэн уйнамыйм да.

Киребеткэн малай булса да, уенның тэмлесе, кызыгы Мөдэррис белэн инде. Кайсы вакытта анын апасы Сания дэ безгэ кушыла. Тик без аңа эллэ ни мохтаж түгел. Менэ Мөдэррис ичмаса... Ул калын яки нечкэ тавышлы сыбызгылар да ясый белэ. Мин дэ ясыйм, билгеле, тик минеке ул кадэр үк уңышлы чыкмый. Кайсыбызны күбрэк ярата икэн ул: Җэмилнеме, минеме? Минедер. Җэмил бит ул чиклэвеген дэ кызгана. Көз җиттеме, эбисе белэн көн саен урманга йөри башлый. Аннары инде ел буе чиклэвектэн бер дэ өзелми. Чокыр буенда туфрак тартырга тегермэн ясаганда да чиклэвек ашарга тотына. Үз итеп кенэ эндэшэбез малайга:

— Җэмил, яле бераз?

— Тагын эзрэк бир инде, э?

— Һич югы бишне сал, ахири!

Ул башта, саранлыгын җиңеп, учлап бирэ. Аннары бишэрне, өчэрне, берэрне. Мөдэррис белэн икебез дэ күзне йомабыз да кулны сузабыз:

— Чиклэвек, төш, төш!

— Кайсыбыз бэхетлерэк икэн?

Җэмил каударланмый.

— Үзегез барыгыз. Монда сезнең өчен муен талдырып йөрергэ,— дип киреләнэ.

Аннары ваграк тагын берэрне бирэ. Янэ сорагач, кулын чиклэвекле кесэсенэ тыга. Болай булгач, башка юмартланмый инде. Энэ ул кабарып торган кесэсенэ таба ничек янтайган.

— Җэмил янтык!

— Янтык, чалыш, саран, карун!

Ачуы килсә дә сугышмый, түзә. Сугышканда чикләвеге коелыр дип курка. Комсыз! Менә шуны ничек дус итәсең ди инде? Ә мин? Булса, чикләвегемне генә түгел, башкасын да кызганмас идем әле. Мөдәррис мине генә дус күрсен берүк!

Менә шул Мөдәррисләргә киттем. Биргән вәгъдәсе дә бар. Ул, әлә-лә, бакчаларында чүп утап ята икән.

— Әйдә бераз уташ әле, Әмир,— диде ул минем килүемә куанып.

Бәрәңгеләре нап-начар, сабаклары да нәзек, чәчәге дә аз. Алабутаны чәчкәннәрмени, шундый котырган.

— Үзебездә дә эш җитәрлек,— дигән булам.— Нигә элегрәк утамадыгыз соң?

— Тагын үскән ул, — диде Мөдәррис.

— Бәрәңгесе зурмы икән әле?

— Яралдымы икән әле, диген ичмасам.

— Ә безнең инде тавык йомыркасы кадәр.

— Сезнең җир әйбәттер.

— Ай-яй чабаклар сикерешә бүген. Су да җылынгандыр инде. Бөгәлҗәм генә начар, малай. Син бергә ясарбыз дип вәгъдә дә биргән идең инде бирүен...

— Тавык йомыркасы кадәр дисең инде, ә?

— Әй-йе.

— Сезнең бәрәңгесе дә тәмле бит, ярмалы.

— Безнең искесе дә ишле әле.

— Искесе нәрсә, көпшәкләнеп, үреп беткән инде ул.

Бакчага Сания килеп чыкты. Мөдәрриснең соңгы сүзләрен ишетеп калып сорады:

— Нәрсә ул?

— Менә, Әмирләрнең яңа бәрәңгесе тавык йомыркасы кадәр ди.

— Қитче!

— Беркөнне караган идек, менә шуның чаклы үскән,— дип йодрыгымны күрсәттем.

— Ялганчы,— диде Сания.

— Нәрсә? Ышанмасаң, үзең барып кара.

— Үз күзем белән күрмичә ышанмыйм.

— Яңа бәрәңге тәмле дә инде ул, — диде Мөдәррис.

— Әмирләрнеке өлгергәч, нигә авыз итеп карамаска? — диде Сания.

— Чынлап та, әллә барып кайтабызмы? —-диде Мөдәррис хиресләнеп.— Бераз чәлдерәбез дә безгә алып кайтып пешерәбез. Аннары печәнлеккә менеп ашыйбыз. Анда әле яңа гына хуш исле печән тутырдык. Их, аулакта сыйлану үзе ни тора! — диде ул телен чартлатып.

— Әнкәй кушмый. Хәзер үк алырга ярамый әле, иртә. Тамыры өзелә аның.

— Һәй, без аны менә болай итеп кенә казыйбыз! — Мөдәррис, ике бармагын тырпайтып, һавада хәрәкәт ясады.— Әнкәң сизмәс тә.

— Белмим. Бөгәлҗәм сүтелеп килә әле минем. Әйбәт саплыкларым да юк. Яңаны әмәллисе иде дә...

— Ясарбыз инде, саплыгы да табылыр. Яңа бәрәңгене әрчисе дә юк, кырасы гына. Сания пешереп тә бирә аны.

— Балчыктан сыбызгы әвәлибезме соң?

— Аны гына инде ике минут бер секунд.

— Яндырабыз дамы?

— Билгеле.

— Әйдәгез!

Бераз бәрәңге алгач, Мөдәррис саплыклары белән бөгәлҗә ясарга кирәк. Аннары сыбызгы. Шытырмаса, яшелгә буялган таш сыбызгыларын Мөдәррис үзе балчыктан әвәләп, утта да үзе яндырган икән. Чүлмәк шикелле. Тепловозныкы сыман калын, чебешнекедәй нечкә тавышлыны дисеңме — төрлесен!

Мөдәррис белән читән өстеннән үрмәләп бакчага кердек. Сания караштыргалап торды, Мөдәррис бәрәңге казыды, ә мин мәкләрне барладым. Кайсы тартмачыклары өлгергән инде, селкесәң, орлыгы учка шыбыр-шыбыр коела. Шундый тәмле! Ә Мөдәррис казый да казый, әйтерсең үз бакчасы.

— Әйдәгез инде, җиткәндер.

— Хәзер. Туйганчы ашарлык алыйк инде, яңа бәрәңге бит ул!

— Кояш кыздыра башлады. Әллә башта су коенып менәбезме? Кара, җитәр инде, кешенекенә айяй юмарт син. Әнкәй белсә, бетерә мине.

Мөдәррис учы белән буразнаны тигезләде дә иелгәләп читәнгә таба йөгерде. Төенчек шактый бүселгән иде. Аларга исән-сау кайтып җиттек тә бәрәңге пешерүне Саниягә тапшырдык. Ул учак ягып җибәрде, без Мөдәррис белән яңадан бакчаларына чыктык.

— Күчтәнәч пешкәнче бераз чүп утыйк инде. Әнкәй эштән кайткач карар.

— Билчәннәре кулны каклый.

— Егет башың белән зарланмасана. Аның кара-

вы дөньяда бәрәңгедән тәмлерәк нәрсә юк та. Яңасы исә күпме ашасаң да биздерми. Ипине күп бүссәң, сару кайный, алма тешне камаштыра башлый.

— Ярып пешергәне дә, чикмәнлесе дә тәмле, әйеме?— дим.— Җәмил булса, бәрәңгеләрен алдыртмас иде әле, бакчаларына аяк та бастырмас иде, әйеме?

— Аны катнаштырмыйбыз да без мондый эшкә. Саран. Бер-ике чикләвеге өчен дә ярты сәгать ялындыра.

— Әйттем ич мин сиңа бергә генә уйныйк, дип.

— Мин аны дус итмим дә. Келәү чокыры буена җир җиләге җыярга барганда да ияртмәдем. Һәй, җир җиләгенең әллә нинди оясын белә ич әле абзаң!

— Мине шунда алып барасыңмы?

— Барырбыз. Безнең бәрәңге бәрәңгемени ул, кара инде, сабаклары да корырга тора. Ә сезнеке...

Горурланып куйдым.

— Тагын алып килербез әле бездән, яме!

Ул арада бакчага тагын Сания килеп чыкты һәм чүп баскан буразналарга күз салып:

— Эшләгез инде, бер дә үрчетмисез,— дип кычкырды.

— Пешәме әле?— дип кызыксындым мин.

— Кайный. Сез тагын икешәр буразна утап бетерешкә өлгерәчәк.

Эшкә дәртләнебрәк тотындык. Тизрәк бетерергә дә... Тик икенче буразнаны чыкканда безне эштән капка тавышы бүлде. Җәмилнең әбисе кереп килә икән.

— Беттек! Бар Санияне кереп кисәт әле,— диде

Мөдәррис миңа пышылдап.— Әнкәй аңа безне караштыргалап торырга кушып киткән. Мин әбекәйне бераз өйгә кертми торырмын.

Әби эшебезне тикшереп маташкан арада өйгә атылдым. Тик Сания инде барын да белә, бәрәңгене табакка сосып алып, аны җәймә белән төреп маташа иде. Сагайган күзләрен ишектән алмастан:

— Өлгереп булмады,— диде ул.— Ярый әле пешеп җитте. Без аны хәзер әйбәтләп яшереп куябыз. Әби озак юанмас, йөри инде шунда кирәкле кишер яфрагы! Ул арада сез су коенып кайта торыгыз.

Өйдә бәрәңгенең авыз суларын китерә торган тәмле исе таралган иде. Үтереп ашыйсы килә башлады. Төкерекләремне йота-йота ирексездән бакчага чыгып китәргә туры килде.

Монда күрше әби исә әле һаман Мөдәррисне кыздыра иде.

—Шушы да эш булдымы инде? Кара әле моны, артыңа бак, моны да утадым дисеңме? Бәрәңге төбендәгеләрен орлыкка калдырдыңмы әллә? Әнкәң кайтса, кирәгеңне бирер әле. Малайлар җыеп, тамаша корып ятасың.— Аннары әби өнәмичә генә миңа таба борылды да:— Бар, Әмир, аздырып йөрмә монда Мөдәррисне, эше күп аның,— дип өстәде.

Менә сиңа кирәк булса! Эшләш, эшләш тә, соңыннан шулай яхшылыгыңны җиргә салып таптасыннар, сөреп чыгарсыннар, имеш! Аздырам, янәсе. Кешегә кереп кысылып йөрмәсә, ни була инде? Калага барырга җыенсаң, Җәмиләңә иптәшкә калыр-

Мөдәррис гайрәтләнгән әби артыннан күз кы-
га бик кирәк булырмын әле, тукта!
сып:

— Су коенып менә тор, аңынчы бетерәм мин,— диде.

Киттем.

Чирмешән буенда иптәшләр шау-гөр килә. Җәмил мине әллә кайдан күреп алып:

— Әмир, йөгер тизрәк,— дип кычкырды.— Суы май кебек, малай!

Ашыкмыйча гына чишендем. Су чынлап та җылынган икән, иптәшләр чыпырдап рәхәтләнә. Тик миңа бүген әллә ни кызык түгел монда. Бер-ике чумып алдым да чыга башладым. Җәмил:

— Син нәрсә, бүтән коенмыйсыңмыни?— дип шаккатты.

— Тәнне чылаткач, җиткән.

— Тукта инде, бераз су чәчрәтешеп уйныйк.

— Уйныйсым килми.

— Әби миңа шәһәрдән яңа кармаклар алып кайтты,— диде Җәмил.— Чабак тота торганны. Әйдә тагын бераз чумып куышыйк инде. Шуннан соң мин сиңа аларның бер-икесен, дус итеп, бирермен.

— Кармакмы?— дидем мин исем китмәгән сыман.— Нәрсәгә ул миңа?

— Синең яхшы кармакларың юк ич.

— Кирәкми дә.

Җәмил башта аптырабрак калды. Аннары янә:

— Бераз бергә уйныйк инде?—дип сагызлана башлады.— Соңыннан чикләвек ашарбыз, мин бүген тагын алып чыктым.

— Кичә бирәләр аны. Хәзер бер минут та вакытым юк!

Тапкан кызыктырыр нәрсәләр. Кармак белән чикләвеккә алданып, бәрәңгене суытып булмый ин-

де, теге әби чыгып киткәч үк сыптырырга кирәк аны. Менә дигән шәп сый! Карчыктан инде, мөгаен, әллә кайчан җилләр искәндер.

Мин тәкәббер генә күлмәк, чалбарларымны төймәләдем дә, Җәмилгә борылып та карамастан, Мөдәррисләргә йөгердем. Минут саен тирләгәч, коенуның да мәгънәсе юк. Печәнлектә салкынчадыр, менәрбез дә сыйланырбыз. Үләннәрнең хуш исен иснәп, ярым караңгыда мәҗлес корып утыру су буендагыларның төшләренә дә керми әле. Аннары я җир җиләгенә, я су коенырга китәрбез. Шуннан соң сыбызгы ясый башларга да мөмкин. Я бөгәлҗә. Йөрсен әле Җәмил кармагын тотып!

Мөдәррисләрнең ишегалдына кергәч, өйдән Саниянең чыркылдап көлгәне ишетелде. Димәк, әбекәй үтүт. Ашыгып ишекләрен ачсам, Мөдәррис белән Сания кара-каршы табынга утырганнар, өстәлләрендә бездән алып килгән, буы чыгып торган ярмалы бәрәңге иде. Тәмле тамакларның яңаклары бүлтәйгән, маңгайларына бөрчек-бөрчек тир бәреп чыккан, рәхәтләнәләр бүсеп. Инде бетереп яталар!

Кермәдем. Ишекне кире яптым да тышка атылдым. Җир җиләге дә, бөгәлҗә дә, сыбызгылар да кирәкми. Миңа берсе дә кирәкми. Я, шуннан соң нинди дус инде син, Мөдәррис?

КЫРДА

Җәйге чиллә. Мин Торнасаз басуында көтү көтәм. Атлаган саен диярлек алдымнан пырылдап тургайлар очып чыга да күккә күтәрелә. Умарта кортлары тукранбаш чәчкәләреннән безелдәп бал җыя.

Минем дә шундый талмас канатларым булса икән! Чәчәктән чәчәккә кунып, көннәр буе очар идем. Аннары тукранбаш кырына кереп йөдәткән кәкре мөгезле тәкәббер тәкәне нәфесенә артык бирелгәндә генә килеп чагар идем. Я булмаса тургай сыман югары менәр идем. Көтүдән аерылучы азгын сарыкларга таш кебек атылып төшәр идем дә...

Мин хәйран калып шул тургайларның сайравын тыңлыйм. Алар зәңгәр биеклеккә менә-менә нәни нокталарга әвереләләр. Ничек башлары әйләнми диген!

Көтүчеләргә яңа туган бәтиләрне алып кайтырга ат бирделәр. Мин шул җирән алашага атлансам, йөрәгем тырсылдап тибә башлый. Әллә очарга ашкына микән? Тургайлар җырын тыңлаганда да шулай канатлана ич.

Агарып килгән арыш кыры, зәңгәрсу-кызыл, шәмәхә-кызыл тукранбаш, «челдер-р-р, челдер-р-р» итеп өзлексез сайрашкан тургайлар көтүгә чыккан беренче көннәремне искә төшерә.

...Отряд сборы бара иде.

— Җәйге каникулда уйнап йөрү генә ярамас,— диде Җәмил.— Мин менә яшелчә бакчасында эшләүче әниемә булышачакмын. Хәзер әйбәт кенә укый башлаган Әмир дә бәлки...

Шулай диде дә миңа карап шып туктады. Бөтен отряд миңа төбәлде.

Башта Җәмилгә ачуым чыкты. Тота да тыкшына. Ни эше бар аның миндә? Малайның борынына чиертәсем килеп китте. Тордым да шар ярып әйттем:

— Ә мин каникулда әткәй белән көтү көтәргә чыгам!

Сбордагы иптәшләремне шаккатыру күңелле иде дә, беренче көннәрдә күземне ертып, ачы таңнан көтүгә чыгулар җиңел булмады. Ул чакта бу тукранбаш, арышлар ямь-яшел иде әле. Тургайлар да болай ук дәртле сайрамый, очынып күккә күтәрелми иде кебек. Хәзер ярыйсы ук бәәлдәшкән бәрәннәрнең дә тавышы нечкәрәк иде. Тора-бара мин дә күнегә төштем. Әткәй яңа туган бәтиләрне авылга илтә киткәндә, малларны берүзем дә караштырып йөрттем.

Менә бүген дә көтүдә мин. Күлмәгемне салып, җиңнәре белән билемә бәйләдем. Беләк һәм иңбашларым инде кояшта янып каралырга да өлгерде. Кушъелга үзәнлегенә таба күченгән маллар артыннан атлый-атлый, аллы-гөлле чәчәкләргә, чутылдап сайрашкан кошларга карап хозурланам. Күкрәк киереп сулый торган хуш исле һава, күз күреме җитмәслек иркенлек. Шуңа күрә башка дөньяларда эшем юк.

Әмма дөньяның миндә эше бар икән. Еракта элек бер кара нокта пәйда булды. Ул миңа якынлаша-якынлаша сулуы капкан Җәмилгә әверелде.

— Тизрәк тукранбаш басуына чап, төенчегеңне барла! — диде ул килеп җитәр-җитмәс.

— Аңа ни булган?

— Җиләктән кайтып килә идек әле без. Тукранбаш басуына җитүгә: «Уф, әйдәгез утырып ял итик инде», дидем. «Эчәсе килә, кайтыйк тизрәк,— дип каршы төште Мөдәррис.— Беләсезме, ничә чынаяк

чәй эчәр идем мин хәзер?» «Ашыйсы да килә, яшьти», дип бүлде аны Зәки.

— Ул шуннан башканы белми дә!— дип көлдем мин Җәмилгә карап.— Җиләген дә кызыл чүлмәгенә генә тутыргандыр әле?

— Әйе шул. Тик мин башлаганымны сөйләп бетерим инде. Кайтабыз шулай,— дип сүзен дәвам иттерде дустым.— Бер заман тукранбаш кыры да бетте. Уңда көтүлек җире башланырга торганда гына Мөдәррис: «Дуслар, тукранбаш арасында нәрсә ята ул?» дип кычкырып җибәрде. Без, ул күрсәткән якка борылып, уздырыштан шунда йөгердек. Алдан барып җитүчеләрнең: «Малайлар, төенчек!», «Сулы шешәсе дә бар», «Суы миңа, яшьти!» дигән тавышлары ишетелде.

— Юлыгыз уңган икән,— дидем Җәмилнең миңа нәрсә хәбәр итәчәген чамалап.

— Сабыр! — диде ул түземсезләнеп.— Килеп җиту белән азыкны бүлешеп яткан иптәшләремә: «Туктагыз! Әмирнекенә охшаган ич бу!» — дип кычкырдым. «Әмирнеке?» — дип ышанмаган булды Зәки. «Яле кире салыгыз әйберләрен!» — дидем мин аның саен. Әниең тамак ялгарга дип биргән корысарыны бер күрү белән төшенеп алдым. Тик тегеләр һаман күзләрен кыздыра.

— Бигрәк тә кайсысы нәфесен сузды соң?

— Мөдәррис белән Зәки. «Әми-и-ир!»,— дип кычкыра башладым. Мөдәррис ул арада бөкесен ачып, шешәңне авызына да каплады. Мин тартып алганда ул аның яртысын бушаткан иде инде.

— Менә ач күз! — дидем мин ни әйтергә белми.

— Алар көнозын су буенда чыпырдый я урамда

уенда онытыла. Ә син колхозга булышасың, отряд данын яклыйсың. Шуңа күрә: «Хәзер Әмирнең үзен алып килим әле», дидем дә монда йөгердем.

— Алар әле һаман шундамы?

— Мин монда йөгергәч, малайлар да авылга таба кузгалды. Әмма алар ерак китәргә өлгермәде, Мөдәррис кире борылды. Башка малайлар иңкүлеккә төшеп күмелгәнне көтеп, атлар-атламас кына килде дә төенчек янына чүгәләде. Тагын бер каранып алгач, шундагы ашамлыкларны бүсә башлады. Үз күзем белән күрдем, йөгер, яшьти! Шундадыр әле ул.

Алашам янымда гына иде. Җәмил тукранбаш басуындагы хәлләрне сөйләп бетерүгә, мендем дә атландым. Үкчәләремне шапылдатуым булды, җирәнкәй томырылып чаба да башлады.

Тукранбаш басуына «ә» дигәнче килеп җиттем. Тояк дөпелдәвен ишетепме, төенчегем янына чүгәләгән карачкы дерт итеп аягына басты да үреләүреләтавыш ишетелгән якка карады. Кушъелга үзәненнән менеп килүемне күргәч, иелә-иелә бар көченә арыш арасына томырылды, аннары кыеклап юл борылышына...

Чаптырып туп-туры төенчегем яткан урынга килеп җиттем дә җиңел генә шуып җиргә төштем. Төенчегемне кулга алып, азык төрелгән кәгазьләрне капшадым. Ялтыратканнар!

Кояш кыздыра башлагач, мин калкурак бер җиргә утырып, менә шушы төенчектәге коры-сары белән тамак ялгый идем. Яшел кырлар, болыннар кочагында тургайлар, чикерткәләрне тыңлау, терт-терт сикергәләп йөргән иркә бәрәннәргә карый-

карый хәл җыю, сыйланып утыруга ни җитә! Иртәнге караңгыдан торсаң, көн ул бик озын, ай-һай озын икән. Төш җиткәнче дә әллә ничә мәртәбә ашыйсы килә.

Мин тагын Кушъелга ягына карап алдым да, атымны авыл юлына борып, чыбыгымны болгадым. Бераздан тып-тып йөгерүче Мөдәррисне куып җиттем.

— Тукта!

Малай борылып та карамый табанын ялтырата бирә.

— Тукта дим! Хәрәм сый хәл керттеме әллә?

— Мин аша-а...

Юлына аркылы төшкәч, очкылык тоткан Мөдәррис сүзен әйтә алмый торды. Әллә ул минем атка атланган булуымнан юашланган, әллә үзем бик гайрәтләндем, аның җиләкле тырысына төшкән кыяр кабыгына бармак белән төртеп күрсәтеп:

— Танма! Әнә бүрегең яна! — дип кычкырдым.

Кулымдагы сыек тал чыбыгын баш өстемдә бер уйнатып алган идем, малаем, чыбык тимәс борын, җиргә тәгәрәде. Бирергә иде дә бит кирәген, җаны үкчәсенә йөгерүен күргәч, сүтелдем. Ник кулымны буйыйм әле шул куян йөрәккә кагылып? Кичен авылга кайткач, Мөдәрриснең мин кизәнмәс борын юл тузанына мәтәлүен малайларга тәмләп сөйләп бирсәм, шәбрәк булыр. Кыңгыр эше белән оятка калуына үзе дә үкенер!

Җиргә сеңгән Мөдәррис тирәсендә тыпырдаган атыма үкчәләремне кактым да Кушъелга үзәненә юырттым. Үч алырга дип эләктергән чыбыгымны ат өстендә тагын бер болгадым да кырыйга тондыр-

дым. Ә җирәнкәйгә нәни хуҗасының чыбык күрсәтүе дә кирәкми иде — очты гына!

— Я, куып җиттеңме? — дип каршылады мине үзәнлектән менеп килгән Җәмил.

— Мөдәррис икән шул тәмлетамак. Хәер, үзенең дә өнен алдым!

— Кыйнадыңмы?

— Кулым кычыткан иде дә, тимәдем. Миннән булсын яхшылык!

— Эчеңдә бүреләр улыйдыр инде... Мә, җиләк аша.

Ач яңаклы, почык борынлы Җәмил тырысының капкачын ачты да түбәтәемә җиләген бушатты.

— Җитте, җитте, син нәрсә!

— Әллә өйдән дә берәр нәрсә китереп китимме? Мин аның киң күңеллелегенә шаккаттым.

— Юк, юк, син нәрсә. Монысына да рәхмәт. Кирәк булса, ат үземдә, кайтам да килəм.

Җиләк белән тамак ялгагач, Җәмилгә:

— Әйдә минем артка менеп атлан, үзеңне бераз озатып куйыйм,— дидем.

— Ә кәтү?

— Эткәй бар ич. Мин тиз әйләнеп кайтам.

Өзәңгегә басып Җәмил өскә атылды. Ат пошкырып кузгалды. Иген кыры уртасыннан тирбәлә-тирбәлә хозурланып барган Җәмил:

— Җиләккә бармый каласың инде син,— дип пошынды.

— Ә без көзен бергәләп гөлҗимеш җыярбыз. Аның оясын миннән генә сора инде син!

— Отряд алган йөкләмәне бер-ике баруда үтәячәкбез, ә?

— Билгеле.

Без шулай сөйләшә-сөйләшә тау битенә килеп җиттек. Астагы үзәнлектә авылыбыз җәелеп ята иде. Җәмил аттан төште дә, булды, дип кулын селкеде.

Мин аның җиләге яртылаш кына калган тырысына, аннары малайның үзенә ягымлы караш ташлап, менә кем ул чын дус, дип уйладым. Аннары атымны Кушъелга үзәненә бордым. Әле кичкә кадәр ерак, көтүне кырлар буйлап тамаклары туйганчы йөртәсе бар иде. Тик мин ирегергә уйламадым да. Баш өстемдә, биектә-биектә, яңгыраган тургайлар җыры яланда көн уздырырга сихерли иде сыман.

ЯРЫШ

Атның әйбәте электе. Дилбегәне кагуга ук юрта башлый. Бахбайларны алмашыйк әле, дип Зәки юкка гына теңкәгә тимәде инде. Әрсез черки кебек аптыратты. Акылы алтын икән, юкә биреп каеш алмакчы.

— Я, малкай!

Җирән кашкага кем дә дүрт куллап риза, әмма үзем чаярак кайнаштым шул. Арбасы да уңай, йөгемне исән-сау мәктәпкә илтеп җиткерсәм, күпләрнең борынына чиртәчәкмен.

Бүген генә башладык әле без бу эшне. Бер дә истә-оста юк чакта яныбызга Рәҗәп абый килеп чыкты. Тегене-моны сорашкалап торгач:

— Чөгендер чүбен утадык, уракка төшкәнче бү-

тән мәшәкать булмас инде, дигән идек. Бар икән шул әле,— дип әйтмәсенме!

— Эш мәңге бетми лә ул.

Гәрәй шулай диде дә черт иттереп төкереп куйды. Зәкинең дә класс җитәкчебез сүзләренә исе китмәде. Күзләрен ялтыратып карап алды да өстәде:

— Әле туйганчы су да коенганыбыз юк.

— Нинди мәшәкать соң ул? — дидем мин.

— Тимер-томыр җыю планыбыз тулмаган бит.

— Укырга кергәч тутырырбыз әле,— диде Зәки.

— Көзен бәрәңге, чөгендер аласы да була шул.

— Алайса кышын...

— Кышын кар астыннан нәрсә таба аласың? — диде Рәҗәп абый.

Чыннан да, тимер-томырны менә хәзер җыюдан да яхшысы юк. Җитмәсә... җитмәсә, бер оясын да беләм әле мин аның. Бер түгел, ике план үтәрлек хәзинәне. Шул нефтьчеләр ташлап киткән яраксыз торбалар, әллә нинди манаралар өемен инде. Җир маен эзләп йөрделәр-йөрделәр дә, күпме бораулап та эш уңмагач, юкка чыктылар безнең яктан. Алабута урманы арасында тутыгып беткән кәкре-бөкре нәрсәләре генә торып калды.

Мин уемны сизмәгәйләре тагын дип, як-ягыма каранып алдым. Юк икән, малайлар барысы да кәләпүшләре белән киңәшеп утыра. Бигрәк шәп. Шыпырт кына әлеге хәзинәне илтеп тапшырсам, барысының да күзен дүрт итәчәкмен. Беренчелек абзагызда булачак!

Шундый хыялларга бирелеп:

— Ә ничек илтербез соң без аны? — диюемне сизми дә калганмын.

— Колхоз атлар биреп торачак, — диде Рәҗәп абый.

Менә шуннан соң тотынган идек без бу эшкә. Үзең хуҗа булып ат җигү, арба доңгырдатып узышулар начармыни? Дөрес, һәммәбезгә дә ат эләкмәде, чиратлашып илтергә туры килә. Әмма китек таба, иске кыршау ише нәрсәләр җыеп кына әллә ни үрчетеп булмый ул. Бар байлыгың арба төбен дә күмеп җиткермәгәч, ат нигә?

Зәкинең менә башы эшли, ат җикте дә без мыштырдаган арада елдам гына трактор паркына элдерде. Белә шәп калҗаны кайдан эләктерәсен!

— Яле-е, малкай!

Йодрык хәтле гайкаларга да яраклы ачкыч алдым әле. Әгәр вышка тимерләрен сүтеп төясәм, кая ул малайларга минем белән тиңләшү!

Юк-бар белән вакланып тормадым, килеп җиту белән атны чигендереп, арбаны вышка астына керттем. Иплэп кенә гайкаларны борып алуым булды, манараның бер өлеше лып итеп арбага төште дә утырды. Җирән кашкам гына әзрәк өркеде, ахры, кырын-кырын карап пошкырып куйды.

— Яле, җирәнкәй, кузгалыйк!

Әмәлен тапсаң, эш бара ул. Җаен беләм инде, югыйсә бу алыпны ялгызым күтәреп арбага салу кая ул! Биш тишек борын тырышса да, кымшанмаячак. Ничә пот тартыр икән? Әгәр тагын бер уралсам? Тик менә Зәки белән Гәрәйнең артымнан карап калулары гына шикле.

— Бахбай, әйдәле!

Камчымны бер болгаган идем, кашка атым кинәт тартылып чаба башлады. Әмма көтмәгәндә арбам гөмберт бер якка! Ә үзем атылып җиргә килеп сыландым. Исемә килгәч, ни күрим: арткы көпчәкләремнең берсе төшеп калган, күчәр башы үлән арасына чумган! Җирәнкәй, мине гаепләмисеңме дигәндәй, миңа койрыгын болгаштыра.

Эчемә салкын йөгергәнлектән, кая аны ачуланып торулар. Арбаны тирәли әйләнеп чыккач, ярый әле бу вышка кисәге өстемә төшеп үземне сытмаган дип сөендем. Маңгаема чыккан тирне сыпырдым да ун адымлап ераклыкта аунап яткан көпчәкне алып килдем. Чәкүшкәне исә байтак ара киткәч кенә таптым. Әмма ялгызыма көпчәк кидерүне уйлыйсы да юк иде.

Инде нишләргә? Малайларның барысы да төрле якка таралган, якын тирәдә берсе дә күренми. Житмәсә, авыл да шактый ерак. Менә ярыш инде хәзер! Күр дә тор, Зәки тантана итәчәк болай булгач. Их!

Күчәрне күтәрергә чамалап караган идем, селкенми дә. Йөкне бушату да хәлемнән килми. Тоташ тимер кантары, сүтәрлек җире дә юк. Менә капты-ы-ым! Ничек котылырга инде бу бәладән?

Шул вакыт күз күреме җирдән арба доңгырдатып килүче бер атлы күренде. Мин аңа кулымны болгап:

— Монда кил әле-е-е! — дип кычкырдым. Атлы миңа таба борылды. Җан-фәрман чаптырып якынлашучы малай Зәки иде. Ул арбасыннан төшеп тормыйча гына:

— Ни булды? — диде.

— Курәсең ич, — дидем мин җирне сөзгән кү-нәргә башымны изәп. — Әйдә көпчәкне кидерик әле бергәләп.

— Фью! Шуның өчен чакырдыңмы? — диде ул атын кире бора башлап.

— Ярдәм итеш инде әйдә?

— Ашыгам, вакытым юк, малай. Аннары икәү генә булдыра да алмыйбыз аны. Көчем җәл түгел, ипидер. Хәлемнән килсә, мин аны синең хакка үзем генә дә...

— Ярар, сандугачны җыр белән сыйлама!

Зәки камчысын уйнатып урман буена таба борылды да атын куалый-куалый иңкүлеккә төшеп күздән югалды. Беләм инде, тимер-томырны барыбыздан да күбрәк җыярга ашкына ул. Минем бәлагә тарып, ярыштан төшеп калачагыма сөенгәндер дә әле, мөгаен. Җитмәсә, кая диген, шул мин белгән «оя»га таба чаптыра!

Утырам кыр уртасында япа-ялгыз. Җирән кашкам койрыгы белән шап та шоп чебен куа, ул чебен генә кумый, әнә шулай күңелемдәге авыр уйларымны да тарата сыман тоелды миңа. Менә сиңа беренче урын, тот капчыгыңны! — дидем мин, шулай да эчемнән янып. Берәүнең дә миндә ваемы юк, малайларның барысы да үз эше белән әвәрә хәзер. Кур әле Зәкине, булышырга дигәч, коты очты. Күзгә төтен җибәреп ачу китерә тагын, сайрап кына судан коры чыга, имеш! Әгәр бүтәннәр дә шулай итсә? Нишлим инде хәзер?

Озак утырдым мин шулай. Малайларның күбесе авыл тирәсендә генә әзләнеп йөри иде. Шунлыктан

мин бәлагә тарыган тын почмакта арба доңгырдавы бары кичкә таба гына ишетелде.

Әйе, җирән кашкам, койрыгын болгап, минем икеләнүемне дә куып тартты. Мин ялт сикереп тордым да авыл ягыннан менеп килгән атлыга кул болгадым. Әмма бу юлы кычкырасым килмәде.

Күрде, барыбер күрде ул мине. Тиз арада яныма да килеп җитте. Җиңнәрен сызганган, башына такыя кигән Гәрәй икән.

— Көймәң комга терәлдеме? — диде ул арбама күз салу белән.— Күптән утырасыңмы?

— Иртәдән бирле.

— Бу якка Зәки менеп киткән иде ич.

— Әй шуны! — дип кулымны селтәдем.

Гәрәй сүзсез генә атын тугара башлады. Нишли инде бу, ди аптырый калдым. Ул арада иптәшем алашасын елдам гына арбадагы печәнгә кушты да алгы күчәренең чәкүшкәсен бәреп чыгарды.

— Мин күтәреп торганда тәртәне салдыр әле!

Гәрәй аны арбамның җиргә кадалган күчәре астына тыккач кына иптәшемнең ниятен аңлап алдым: тәртә белән күтәреп эшне җиңеләйтергә тели иде ул.

Без әле тәртә белән дә күчәрне кочкә кузгаттык. Көпчәк кидерергә исә өченче кеше кирәк иде. Азапланып күтәргән күчәрне кире төшерергә туры килде.

Икебез дә мышнап чыккан идек. Маңгай тирен сөртә-сөртә утырып ял иттек. Аннары тагын арба тирәсендә әйләнә башладык. Нинди хәйләсен табарга инде бу эшнең? Озак баш ваткannан соң Гәрәй шатланып:

— Дуга бар ич безнең,— диде.— Булдырабыз хәзер!

Күчәрне баягыча тагын күтәрдек тә дуганы рычаг-тәртәнең үзебез күтәргән башы астына бастырып куйдык. Авырлык дуга өстенә күчте. Хәзер инде беребез читкә дә китә ала иде. Мин шундук тәгәрмәч янына атылдым һәм аны күз ачып йомганчы күчәргә кидереп тә куйдым. Уф! Җилкәмнән тау төшкәндәй булды, авызым ирексездән ерылды. Миңа хәзер кузгалырга да мөмкин иде инде!

Тик мин ашыкмадым, дөресе, ашыгырга яхшысынмадым. Бергәләп Гәрәй арбасының тәртәсен куйдык, аннары икәүләшеп атын җиктек. Тыштан сер бирмәсәм дә чынлыкта түземсезләнүемне иптәшем шулай да сизгән иде, ахры.

— Син борчылма, Әмир,— диде ул,— Зәки барыбер уза алмас. Әгәр уза башлый икән, үземнең тимер-томырны синекеләргә өстәрмен. Минем барыбер сезнекеннән әзрәк ич.

Әллә мәнсезлегемә суктыра шунда? Оялтырга чамалыймы? Ачуланырга хакым юк, үртәсә дә чыдарга кирәк. Шуңа күрә таң калгандай:

— Ничек инде?— дип сорадым.

— Шулай.

Мин инде ярдәме өчен Гәрәйгә болай да нинди генә рәхмәтләр әйтим икән, дип тора идем. Вакыт Зәкигә генә түгел, аңа да кадерле ич. Үз эшен калдыру хисабына булышты лабаса ул миңа! Ә бу юмартлыгы...

Күңелемә әллә нәрсә булды: шатлыктан елыйсы, җырлыйсы, дөньяны яңгыратып кычкырасы, Гәрәйне кысып кочаклыйсы, мәтәлчек атынасы

килә, әмма үзем һаман катып калгандай тора бирәм.

— Мин нефтьчеләр хәзинәсеннән коры калдым бугай инде,— дип өстәде Гәрәй.— Таралып ятканын Зәки җыеп бетерәчәк. Тоташын төяргә көч җитеп бетмәс. Әйдә синекен бушатырга гына ярдәм итим дә...

— Юк, юк,— дидем мин исемә килеп,— мин сиңа ачкыч бирәм, сүтеп алырсың. Хәзер бу албастыны кайтарып бушатам да үзем сиңа булышырга менәрмен. Сиңа өлеш чыгачак әле, анда, тагын да саллырак калҗаны табарбыз. Беләсеңме, беренче урынга син үзең лаеграк ич, Гәрәй!

Җирән кашкам колакларын торгызып безне тыңлый иде. Акыллы җан иясе шул ул, яхшы сүзне җилгә очырмый. Мин аңа кузгалыр вакыт җиткәнлекне белдереп дилбегәне кактым:

— Әйдәле, дускай, сынатмыйк, яле!

САРАН КҮРШЕ

Бөркү көннәрне капка буендагы күләгәдә утыру рәхәт. Әнә бүрәнә өеменә бүген дә күрше кызы белән Айнур менеп кунаклаган.

— Без былтыр бу вакытта диңгездә су коена идек, —ди Зөлфия.

— Тотасың да шул диңгезең белән мактанасың.

— Эссе ич. Мондый кызуда дулкыннар белән куышып уйнавыбыз искә төшә. Анда кешене бер кабуда йота торган кит балыклары да бар.

— Шыттырма, яме! —ди Айнур ачуланып.— Кит балыгы Кара диңгездә юк ул.

Айнур башта Зөлфия сөйләгәннәрне йотлыгып тыңлаган, алып кайткан кабырчыкларын сыйпап-сыйпап та караган иде. Хәтта шундый нәрсәләр аунап яткан яр буенда йөрисе, дулкыннарда тирбәлеп йөзәсе дә килгән иде. Әмма Айнур соңыннан велосипедны сайлады. Нәрсә ул диңгез, аны кесәгә салып алып кайтып булмый. Ә «сәпит»тә җәй буе рәхәтләнеп йөрисең. Икенең берсе, дигән иде этисе, вәгъдәсен үтәде менә!

Шулчак тагын Зөлфия тавышы яңгырады:

— Без быел да еракка китмәкче әле.

— Кая? — диде Айнур.

— Кырымга. Анда пальма, йөземнәр үсә. Карбыз, кавын...

— Ә без авылга кайтабыз. Анда карлыган, кура җиләге, юа, кәҗә сакалы, тагын әллә нәрсәләр белән сыйланасың.

— Ә без «Җигули»да барабыз. Чабаксар, Горький, Мәскәү — юл уңаенда ничәмә шәһәргә тукталачакбыз!

Бирешергә исәбе юк иде Айнурның, тик менә шулкадәр шәһәрләрне санагач... Их, дәү этиләре дә бигрәк якында гына шул. Өйдән чыгып авылны узуга, кайтып та җитәсең. Ул авылларны телгә алып кына җиңеп буламыни Зөлфияне? Юк, билгеле. Барсыннар иде алар да шул ерак-ерактагы диңгез буена, кызыктырып сөйләнә алмас иде бу кызый.

— Сез кайчан машина аласыз соң әле?

Зөлфиянең яңа соравы Айнурның кәефен бөтенләй бозды. Ни дә булса әйтеп, борынын төшерергә кирәк, дип уйлады ул эченнән.

— Ә синең этиең саран. Акча корты!

— Әни «бакча корты» ди тагын. Гел шунда казына ич ул. Җиләк-җимеш, чәчәкләр үстерә. Мин дә булышам.

— Комсызланып йөри инде. Машинасына малайларны бер тапкыр утыртырга да калтырап тора. Үзеңә эт тә асратмый әле.

— Кызларга эт нәрсәгә? Аның каравы мәчебез икәү.

— Әти миңа, бераз үскәч, мопед алам, диде.

— Мопедка күбәү утырып булмый, машина әйбәтрәк. Мопед белән Кырымга ничек барасың инде?

— «Кырым, Кырым»,— дип үчекләде Айнур.— Дәү әтиләр мичендә теләсәң күпме ул корым, кайт та кара.

Юк, торып-торып Айнурның ачуын чыгара бу кызый. Әтисе дә инде берни булса тота да авылга алып бара. Бүтәннәр төсле Кавказга я Кырымга гына төяп китсә дә ярый ич Айнурларны. Нәрсәгә акчасын җәллидер. Зөлфия шикелле, кабырчыклар җыярлар, пальма асларына ятып тәгәрәрләр, иртәдән кичкә кадәр кызынырлар иде. Юл буе дөнья күреп йөрүе дә кызык ич әле. Машина сатып алмыйча аптыратты тагын. Әйтергә кирәк әле үзенә бу хакта!

Әмма этисе эштән кайткач, Айнур сүзне Зөлфиядән башлады.

— Ул шундый мактанчык, минут саен Кырым дип авыз суын агыза. Имеш, аның әтисе телевизор да төзәтә, радио да рәтли белә. Имеш, бакча да үстерә. Аны акча сугар өчен генә үстерә ич Галимҗан абый, әйеме, әти?

— Туган көнеңә чәчәкне бушлай керттеләр түгелме соң?

— Туган көнгә ич ул. Галимҗан абый Зөлфияне дә карап кына тора. Киемеңне буяма, уйнаганда иске сандалың да ярый әле, дип кызының колак итен ашый. Саран!

Әти кеше елмаеп:

— Дөрес кисәтә ләбаса,— диде.

— Син миңа өч сәпит алдың ич инде, әйеме, әти? Башта өч тәгәрмәчлене, теге мин нәни чакта урамда калдырып кайтканны. Аннары кибет янында югалтканны. Хәзер менә тагын яңаны!

— Әйе.

— Ә Галимҗан абый Зөлфиягә бары берне генә.

— Алар машинага тырышты шул.

— Юк инде, барыбер саран ул. Машинасына утырта башласа да, ботинкаң шакшы түгелме, дип сорый. Мал җанлы. Ә син менә безнең өчен бернәрсәне дә кызганмыйсың. Командировкага баргач та күлмәкләр алып кайтасың.

— Кирәк бит, улым.

— Галимҗан абыйны яратмыйм мин. Телевизорыбызны бер-ике тапкыр борып караган өчен дә акча алды.

— Яңа детальләр куйды ич ул аңа.

— Куйса соң. Күрше хакына инде... Менә мин Галимҗан абый урынында булсам...

— Нишләр идең?

— Юк, минем аңа охшыйсым килми. Мин синең шикелле булыр идем. Каникулда авылларга кайтыр, кайсы елларны диңгез буйларына барыр идем.

— Хәйләкәр дә инде син!

Әтисенең елмаеп торуын күреп, Айнур тагын да батырайды.

— Әти, без дә машина алырбыз әле, ә?
— Нәрсәгә соң ул?
— Менә Кырымга барырга.
— Ай-яй синең планна-а-ар!
— Алыйк инде, әти, ә?
— Әйдә, диван астындагы әйберләрне җыештырыйк әле. Мин күтәреп торам, син тартып чыгар.

Диван астыннан Айнурның югалттым дип йөргән ике пистолеты, кылычы, пычракка батып кайткач яшергән чалбарлары — бер кочак әйбер табылды. Аннары алар әтисе белән икәүләп караватъ, шкаф асларын да бушаттылар. Коридордагы әрҗәгә, стена куышындагы шүрлекләргә дә күз салдылар. Бөтен җирдә Айнурның я төймәсе өзелгән күлмәге, я буявы кырылган өчен генә кими башлаган ботинкасы аунап ята икән ләбаса. Әти кеше шуларга баш изәде дә:

— Син вакытыннан алда яраксызга чыгарган киемнәр Каф тавы чаклы икән,— диде.— Тау карарга көньякка барасы да юк. Айнур безне бер киде дә ташлады, дип ул киемнәр түккән күз яшеннән зур бер диңгез җыелгандыр инде, мөгаен.

Айнур дәшмәде. Аңа әтисе чебеннән фил ясый кебек тоелды.

— Бәлки миңа Галимҗан абыеңнан, ә Айнурга Зөлфиядән үрнәк алырга кирәктер? — диде әтисе.— Юкса син бер киясең дә тотып атасың киемнәрне. Аннары тагын яңасын сорыйсың. Машина алырлык мая җыюны уйлыйсы да юк болай. Ә син безнең ничек үскәнне беләсеңме?

— Ничек?
— Әйдә утыр әле яныма. Бераз сөйлим үзеңә.

* * *

Сугыштан соңгы еллар иде. Мин дә бер заман сезнең шикелле укырга кердем. Элек үзебез урам малайлары белән генә уйнасам, мәктәпкә инде бүтәннәр белән дә таныштым. Иптәшләр күбәйде, дөнья киңәйде, рәхәт!

Шулай да артымда гына утырган Галимҗанны шактый вакыт юньләп белмәгәнмен икән. Аның белән язга чыккач кына дуслаштым. Ул апрель аенда да класста бишмәтен салмыйча утыра иде. Әле аны кояш кыздыра башлагач та ташламады. Бишмәтенең чабуы берничә җирдән ямалган, якалары, җиңнәре каешланып беткән.

Галимҗанның укуы әйбәт, класста иң яхшы укучылардан. Мактанчыклык та бар иде, ахры. Укытучы: «Кем җавап бирә?» — дигәч, беренче булып кул күтәрә. Ничек кенә итеп күтәрә иде әле! Кулын бөтен буена суза, үзе: «Мин, мин сөйлим», дип очынып-очынып та куя. Аның кыланышы шул кадәр көлке тоелды, пырхылдап җибәрүемне сизми дә калдым.

— Рамазан, яле син сөйлә? — диде шулчак укытучы.

Ни сораганын ишетми калганга күрә, ярдәм өмет итеп як-ягыма карандым. Тик һәрчак ярдәмгә әзер иптәшләрем бу юлы ашыга-ашыга китап актара, кайсы укытучыга караган, кайсысы дәреслеккә иелгән дә төмсәләнеп утыра. Үзеннән сорамаганга кәефе кырылган Галимҗан тагын җанланды. Кулы бер күтәрелә, бер төшә, сәгать телемени! Үземне белдекле күрсәтер өчен генә иптәшемне шулай сатаммы

соң? Пышылдаса гына ни була инде шунда! — дип уйлыйм.

— Я, я, Рамазан, сөйләп җибәр. Нәрсә, әзерләнмәдеңмени?

Ишетми калдым, дип әйтеп булмый ич инде, куйса куйсын шунда икелене, ишетми калу тәртип бозуга керә, ул, дип уйлыйм, үзем Галимҗанга теш кайрыйм. Очынуы бигрәк чамасыз. Бишмәт сөйрәп йөри, югыйсә нинди җылы көн инде. Мин бер атнадан бирле мәктәпкә дә яланөс йөгерәм. Утыргач та ачуым басылмады, әйтерсең гаепнең бөтенесе шул Галимҗанда иде. Тәнәфескә чыккач ук бәйләнә башладым:

— Малайлар, Галимҗан корчаңгыдыр ул! Таз бүреген, корчаңгы бишмәтен салмый. Әйдәгез берәрне тамызыйк әле, йодрыкны тояр микән? — дим.

«Үзем сөйлим», дип гел кулын күтәреп утыруына башкаларның да ачуы җыела килгәндерме, минем яклылар хәтсез иде — минуты белән умарта күче кебек сырып алдык малайны. Галимҗаныбыз бoжрадан чыгып ычкынганчы, иптәшләремнең берсе тамызып та өлгерде. Икенчесе дә ярыйсы кундырды, мин дә берне сыладым! Тик шул мизгелдә үземнең дә күз алларым караңгыланып китте, малайлар төркеме томанга күмелгәндәй юкка чыкты. Хәерсез Галимҗан бездән җитезрәк хәрәкәтләнде, ахры, минем күз төбенә, кемнеңдер борынына тондырып, класстан чыгып качты. Күземне тотып мин дә, башкалар да аның артыннан атылдык. Тик менә хикмәт, артыннан якынлашып тотам дигәндә генә Галимҗан кинәт туктап җиргә чүгә дә малайларның куып җиткәне бере аның гәүдәсенә сөртенеп тәгәри, ә

«бишмәт» елдам гына сикереп тора да тагын чаба. Эчемнән, хәзер тотам үзеңне, миңа кул күтәрүеңне ташлатам, дип гайрәтләнеп йөгергәндә генә үзем дә шуңа абынып җиргә сеңдем. Терсәк сыдырылып чыкты, чалбарымның тез турысы чирәмгә ышкылып ямь-яшел булды. Галимҗанга нәрсә, аңа рәхәт, бишмәте калын, егылса да бер җире авыртмый. Тик мин тотам дигәч барыбер тотам инде. Менә ул тагын мәктәп рәшәткәсе буйлап йөгерә. Серле бишмәтен саклый, ертылмасын өчен чирәмгә генә аварга ниятли. Бу юлы алдатмыйм инде, дип капылт туктарга әзерләнеп чабам. Тик тагын булмады, тәгәрәдем! Шулай да бу юлы Галимҗанның бишмәт чабуын электереп калырга өлгердем.

Ул торып йөгермәкче иде, шунда бишмәтенең төймәләре тартылып коелып төшмәсенме! Хәтта тышлыгы да умырылып чыкты. Малайны ычкындырмыйча гына торып баскан идем, шаккаттым: бишмәт эченнән ап-ак булып Галимҗанның ябык шәрә тәне күренеп тора. Менә нәрсәдә икән бишмәт салмауның сере. Көлмәге юк икән ич! Аптырап кулымны ычкындырдым, ә ул лышт итеп борынын тартты да тизрәк тәнен капларга ашыкты. Төймә урынында калган җепне сүтеп каптырмага бәйләде.

Без мышкылдап, тирләп чыккан идек. Мин каушый да калдым. Чөнки бишмәтен салмаганга бәйләнүем өчен дә, башкаларны котыртуым һәм аның шул актык киемен эштән чыгаруым өчен дә уңайсыз булып китте. Галимҗанның бу хәлен кеше күрмәде микән, дип як-якка карадым. Бәхетемә, без ул тирәдә икәү генә идек.

Аннары иелеп яшел чирәм арасыннан Галимҗанның коелган төймәләрен эзләдек.

* * *

Әтисе тынып калгач, Айнур:

— Ә нигә куртка гына кими иде соң ул?— диде

— Ул вакытта куртка түгел, майкабыз да юк иде шул. Хәзер менә син, киемне саграк кияргә кушкан өчен дә, Галимҗан абыеңны саран дисең. Синеңчә, Зөлфиягә ул яңа велосипедны да саран булганга күрә генә алмый икән.

Айнур Галимҗан абыйсының балачакта ялан тәненә бишмәт кенә киеп йөрүен һич тә күз алдына китерә алмады.

— Әгәр аның хәзер малай чагы булса, мин аңа бер күлмәгемне бүләк итәр идем,— диде ул әтисенә.

— Без яңадан балага әверелә алмабыз, ә менә сиңа тотнаклылыкка өйрәнергә соң түгел әле.

— Ничек?

— Кешедән гаеп эзләгәнче, тотасың да үз гаебеңне бетерәсең! Әйтик, сиңа ник бераз пөхтәрәк йөрмәскә икән? Бик киң күңелле булгач, яңа сәпитеңне нигә Зөлфиягә дә биреп тормаска?

— А-а-а! — дип өнәмәвен белдерде Айнур.

— Үзеңнеке кызганыч, кеше әйберенә генә юмарт, ахры, син.

Шулчак ишек шакыган тавыш ишетелде һәм бүлмәгә Зөлфиянең әтисе килеп керде.

— Ни хәлләр, яшьти? — диде ул күңелле гөрләп.— Эшләр пешәме? Без тәмам әзерләнеп җиттек инде, сезнең хәбәрне генә көтәбез.

— Әле үзем дә сезгә кермәкче идем, күрше. Быел морадка җитәрбез, ахры, киләсе атнадан риза-лык бирделәр. Хатын гаризасына да кул куйганнар.

— Димәк, барабыз? — диде Зөлфиянең әтисе.

— Барабыз!

Бу сөйләшүдән әле берни аңлап җитмәгән Айнур:

— Кая барабыз, әти? — дип күзләрен ялтыратты.

— Кырымга, улым...

— Урра!

— «Саран» Галимҗан абыең безне үз «Жигули»ена утыртып барачак!

Айнур күзләрендәге очкыннар, әтисе «саран» сүзен телгә алуга, сүнделәр, йөзе кызарып китте. Аннары ул Галимҗан абыйсына карамаска тырышып чигенә-чигенә бүлмәдән урамга атылды. Зөлфиягә яңалыкны әйтергәме, әллә бая чәпчеп китүе өчен гафу да үтенергәме — күршеләренә таба атлаганда моны әле ул хәл итмәгән иде. Чөнки үз гаебеңне тану бик-бик кыен эш ич ул.

КЕМ ГАЕПЛЕ?

Һәр көнне Алсуны кояш уята иде. Юрган астыннан чыккан битенә, беләкләренә җылы нурларын төшерә дә пешерә башлый. Алсу ирексездән күзләрен ачып җибәрә. Тик уянгач та әле ул шаян кояшка иркәләнеп ята. Әти-әнисе инде күптән эшкә киткән була. Алсуның менә беркая да ашыгасы юк — каникул.

Бүген исә әллә нәрсә сискәндерде аны. Ярма чүпләгән чебиләр кебек, кемдер тек-тек-тек итеп тавыш чыгара иде. Әле беләгенә кояш төшәргә дә өлгермәгән, димәк, бик иртә. Шуңа күрә Алсуның

керфекләре бик авыр күтәрелде. Ачылды да тагын йомылды. Тагын бераз гына черем итим дип борылып ятмакчы иде, күзе тәрәзәгә капланган шәүләгә төште. Таң тишегеннән тәрәзә кагучы тиктормас Әлифә икән. Алсуның уянуын күреп булса кирәк, түземсезләнеп:

— Йокы чүлмәге, тор, төш җитә ич! — дип кычкырды.

Ә, шулаймы, кирәк булдыммы? Ялын әле, әнисен көткән кош баласыдай зарыгып бет, юрганын башыннан ук бөркәнер дә куяр Алсу. Күрмәде дә, ишетмәде дә, янәсе.

Тик Әлифә һаман тырнагы белән пыялага чиртүен белде: тек-тек-тек... Ялындыра алуына сөенгән Алсу юрганына тагын да төренәрәк бирде. Шул кирәк сиңа! Кичә капка төпләренә Алсу якынлашу белән Миләүшәне ияртеп койма буйлап йөгерде. Миләүшәне үзенә каршы котыртуын чамалады Алсу. Имеш, ул курчагын да, кашык-тәлинкәләрен дә җәлли, Алсудан башка да бик рәхәтләнеп уйнап була, фәлән дә төгән. Аның пыш-пыш килүен ишетеп торган Алсу Миләүшәнең шул ялганчыга ышануына гарьләнде дә кире борылды.

— Төш күреп ятасыңмы, тор инде? Аю да болай кышын гына йоклый!

Син үзең аю, дип уйлады Алсу. Дусты Зөлфия пионер лагереннан кайтты инде, сиңа ялыныч юк. Кичә Әлифә качкач та дөнья җимерелмәде. Зөлфия белән таган атындылар, кибетле уйнадылар, җиләккә бардылар. Миләүшәне әнисе килеп алгач, үзең безне эзләп йөрдең, келәт ярыгыннан бик яхшылап күзәтеп тордылар...

Ул арада Әлифә тәрәзә янына бүкән тәгәрәтеп китерде дә шуңа басып форточкага үрелде.

— Алсу, борчакка бармыйсыңмыни? — диде ул кычкырып.

Борчакка? Шушы Әлифәдән чыгар җыен тузга язмаган нәрсә. Борчак кузакланса икән әле. Шулай да Алсу күзен ачып:

— Өлгермәгән әле ул,— дип җавап бирде...

— Әйдә инде, Зөлфияләр торып чыкканчы, шыпырт кына ычкыныйк.

— Зөлфия дә барсын, күбәү күңеллерәк була ич.

— Җыйнаулашып йөргәч кеше күрә, иген тап-тап йөрисез, дип әрлиләр. Без икәү мыштым гына барырбыз да туйганчы ашарбыз. Яшел борчакта витамин күп.

— Миләүшәңне дә ияртмисеңме?

— Аны энисе каядыр алып китте.

Ә-ә, менә нигә юмакайланасың икән син, иптәшсез калгансың! Әйтәм аны өтәләнә, мине Зөлфиядән аермакчыдыр. Үзенә кирәктә бал тирәсендәге чебен кебек бөтерелә, минем йомышым төшсә, базарын күтәреп маташа, үртәлеп үләрсең.

— Өй җыештырасы, идәннәр юасы бар әле минем. Аннары Зөлфия белән яшелчәләргә су сибәчәкбез, аларның җиләген җыячакбыз. Аннары...

— Зөлфия саран беләнме? Бер җиләген капсаң да, кайнар күз яшьләрен түгә ич. Уйнаганда да үз тубын алып чыкмый, синекен туздыра.

— Ә мин аңа үзем бирәм. Аныкы кечкенә, сикертергә җайсыз.

Әлифә исе киткән төсле:

— Шул мактанчыкны яклыйсыңмы? — диде.—

Иртән бер күлмәк кия, төш чагында икенчене, кичкә таба өченчене. Байлыгын күрсәтә имеш! Я, киттек-ме борчакка?

— Әй, бармыйм ла,— диде Алсу ачуы килеп.— Миләүшәңне иярт тә йөгер.

Әлифә күздән югалгач та әле, Алсу урыныннан кузгалмады. Хәзер аның өй җыясы да, идән юасы да килми иде. Яшелчәләргә су сибәргә дә ашыкмады. Йокысы туймаса да, кире ятып тормады, чәч очларын бармак башына урап утырды да утырды. Аннары теләр-теләмәс кенә чәчен тарады, урынын җыйды, юынды, әнисе әзерләп калдырган салатны чемченеп кенә капкалады да, эч пошуын басар өчен, урамга чыкты. Олылар эштә, иптәшләре әле һаман шулай ук йокыдан тормагангамы, тирә-якта җан әсәре күренми иде. Ул үзеннән-үзе Зөлфияләргә таба атлады. Күңелендәге шикләрен таратса бары шунда гына тарата ала иде ич ул!

Иптәш кызларының зәңгәр капкалары ачык иде, ишегалдындагы Сарбай аны, таныш кешеседәй үз күреп, койрыгын болгап каршылады. Тик Алсу бу юлы гадәттәгечә аның башыннан сыйпамады, хәтта бөтенләй игътибар итмәде, бик ашыгыч эше бар сыман, җитез генә өйалдына узды. Әмма ишек тоткасына ябышу белән, таныш тавышны ишетеп, кинәт туктап калды.

— Алсу бик кире бит ул, әйеме? Үзен генә ярата,— дип каударлана иде бу тавыш.— Бер сүзне тыңламый. Саран да. Уйнаганда да тубын кызгана,— гел синекен эләктерергә ашыга. Җитмәсә әле «Зөлфия карун», «Зөлфия мактанчык», дип минем колак итен ашый!

— Кичә без аның белән яшелчәләргә су сибәргә сүз куештык,— диде Зөлфия тавышы.

— Һи-и, ышанма син аңар, ялкау ич ул! Сине яратмый да, минем белән дус булуыңнан көнләшә. Мине дә, Зөлфия белән уйнама син, дип котырта. Әле беләсеңме, беләсеңме... ни, ул синең күлмәкләреңне дә күпсенә. Иркә, борын күтәрүчән, ди. Мин, Зөлфия юмарт, Зөлфия киң күңелле, дигән идем, мыскыл итеп көлә башлады!

Алсу үз колагына үзе ышанмады. Ул инде латы-лоты сүз тегермәне коручының Әлифә икәнен чамалап алган иде. Әмма әле яңа гына үзенә: Алсу, син тегеләй, син болай, дип төчеләнеп торганнан соң Зөлфиягә бөтенләй нәкъ шуларның киресен сайравы белән шаккатырды. Җитмәсә, Зөлфия турында үзе хурлап әйткәннәрнең барысын да Алсуга ябыштырды да куйды. Менә юха ела-а-ан! Әгәр Зөлфия шуның сүзләрен чынга алса?

Алсу йөрәге сикерүгә түзә алмыйча лып итеп өйалды идәненә утырды. Сарбай әле һаман яхшатлыланып койрыгын болгый-болгый аңа карап тора иде. Икейөзле, мәкерле булуның нәрсә икәнен дә белмәгән маэмайны иркәләргә кирәклеген Алсу шунда гына аңлап алды һәм, кире ишегалдына чыгып, Сарбайны сыйпый башлады. Этнең тугрылыклы карашы, нәни кызчык дип тормый иркәләнүе Алсуга көтелмәгән көч бирде, ул хәзер нишләргә кирәклеген уйлый башлады. Билгеле, хәзер өйгә кереп кычкырышырга, Зөлфия алдында Әлифәнең кем икәнлеген фаш итәргә мөмкин. Тик алай гына эшне төзәтеп булырмы икән? Ачу басылырмы? Сабак алырмы Әлифә?

Алсу күрше кызын башкача акылга утыртырга ниятләде. Берни ишетмәгәндәй, ишек шакып килеп керде дә:

— И-и, Әлифә миннән дә алда сезнең түргә менеп кунаклаган икән,— диде.

Әлифә сөйли торган сүзне шып туктатты. Зөлфия Алсуны чәй эчәргә чакырды, алдына кыяр, редиска чыгарып куйды. Ул да яңа гына торган, күрәсең, аны да йокыдан иртәнге әрсез кунак уяткан иде.

— Борчакка барырга кыстыймы? —диде Алсу Зөлфиягә.

— Әйе,— дип елмайды дусты.

— Колхоз борчагын урлап йөргәнче, әйдә өйдә генә уйныйбыз,—диде Алсу.— Мин сезне күз йомып инә сапларга өйрәтермен.

— Һи, тиле, күзне йомгач инә саплап буламы инде,— дип көлде Әлифә.— Аны әле болай да...

— Ә менә мин өйрәтә алам,— диде Алсу үзсүзләнеп.— Билгеле, бу эш борчак кырын таптап йөрүдән кыенрак. Тик бер һөнәр өйрәнү начармыни?

— Алайса өйрәт! — диде Зөлфия.

Хуҗа кеше шундук инә белән җеп табып килде. Алсу аларны кулына алды да тәрәзә каршындагы урындыкка килеп утырды. Әлифә бик теләп һөнәрен күрсәтүченең күзләрен капларга ашыкты.

Алсуның күз йомып әллә ничә мәртәбә инә саплаганы бар иде. Бу юлы да сынатмады, тик шулай да аңа байтак мышнарга туры килде.

— Һи, шул кадәр мыштырдагач, кем дә булдыра аны,— диде Әлифә.

— Менә хәзер син мыштырдамыйча гына сапла!

Инә белән җеп Әлифә кулына күчте, Зөлфия учлары белән аның күзләрен каплады. Әй тырыша, әй тырыша Әлифә, әмма инәсе югары очта, җебе түбән очта бутала кызыйның. Мәсхәрә!

Учак тирәсен урап килгән Алсу кәефләнеп:

— Бу сиңа бүтәннәрне ыскыртып йөрү генә түгел,— дип төрттерде.— Кая, Зөлфия, үзем каплыйм әле күзен. Син бик кысасың, ахры, аны, тирләп-пешеп чыкты иптәшебез.

Алсу, Зөлфияне алыштырып, ике учы белән Әлифәнең күзләрен каплады. Аннары, кулларын аның иягенә, колакларына таба да шудыргалап, Зөлфиягә күз кысты да:

— Уф, көнне уздырып бетерерсең, ахры, син. Яшелчәләргә су да сибәсебез бар ич әле. Әз-мәз күзен ачкалап та алмый булмас,— диде.

Зөлфия башта Әлифәгә төбәлеп берни аңламый өнсез калды, аннары шаркылдап көлеп җибәрде. Ниһаять, Алсуның учлары күзен томаламаган мизгелдә Әлифә дә инәсен саплап бетерде һәм бик зур эшне майтарып чыккан кыяфәттә иптәшләренә карады. Зөлфия хәзер инде көлүеннән тыела алмыйча диванга ятып тәгәри, Алсу да кеткелди иде.

— Сез нәрсә, тилердегезме әллә? — диде Әлифә.

Иптәшләре хихылдаудан һаман туктала алмагач, ул шикләнеп як-ягына каранды, тик гадәттән тыш берни дә күрмәде. Бүлмәдә һәр нәрсә үз урынында, өчесенең дә киеме тәртиптә, кызык ясарлык ят кеше дә юк иде.

— Йө-йөзең! —дип пышылдады көлеп хәле беткән Зөлфия.— У-учак...

Әлифә йөгереп көзге каршысына барган иде,

үзен танымады. Йөзе кап-кара, чуен кебек! Кулы белән ышкыган иде, учына битендәге корымы ягылды.

— Сез... сез нәрсә? — диде ул иптәшләренә борылып.— Сез нәрсә?!

Көлү басылды. Уңайсызланган Зөлфия ни әйтергә дә белмәде. Бары Алсу гына бик канәгать төстә:

— Йөзең каралса, көзгегә үпкәләмә. Гаебеңә күрә җәзасы! — диде.

Әлифә инде хәзер битен, маңгайларын күлмәк җиңе, итәге белән ышкый, төкереклэп сөртә, әмма инә саплаган чагында аның йөзенә Алсу хәйләләп тидергән корым һич тә бетәрлек түгел иде. Әлифә ишекккә таба атлый-атлый:

— Сез миңа дус түгел, мин сезнең белән бүтән уйнамыйм да! — дип елап җибәрде.— Тукта, үзегез дә эләгерсе-е-з әле-е-е!

— Ашыкма, кер әле кире, сабын белән юын,— дип чакырды аны Зөлфия. — Син дә инде, Алсу, шулай шаяралармыни?

Алсу дустына Әлифәне ни өчен шулай көлкегә калдыруын сөйләп бирде һәм ачу алырга хакы барлыгын исбатлап:

— Шул кирәк аңа! — дип сүзен тәмамлады.

ШИФАЛЫ СУ

Яшел киемнәрен киеп, тирә-якка күңелле нурларын чәчеп, яз килде. Урамнар хәтфә чирәм белән капланды, су буендагы тал бөреләре ачылды.

Исеме Каенсар булса да, авылыбызда әнә шул таллардан башка агачлар бик әз үсә иде. Хәер, ерак түгел генә каен урманы бар барын, болдырдан күренеп үк тора. Җилле көннәрдә каеннарның бөдрә

ябалдашлары дулкынлануын да чамалап була. Урман шулай әллә кайдан ук безне ягымлы сәламләп үзенә чакырып тора сыман. Әгәр малайлар җыелышып килсәк, йомшак кочагына алыр, баллы хуш ис аңкып торган яфраклары белән битебездән иркәләр төсле.

Менә бүген дә шушы урманга килдек әле без. Һәркайсыбызда пәке, я булмаса пычак инде, билгеле. Башта бура таяклары, аннан соң кармак саплары, бөгәлҗәлекләр кистек. Каеннан алар шәп чыкмый чыгуын, тик нишләмәк кирәк...

Каеннарның бөреләре яңа гына ачылып, аннан ямь-яшел сабый яфраклар борынлый башлаган. Урман әле кышкы йокысыннан уянып кына килә. Кошлар чутылдашуына таң калып, колак салып торабыз — күңелле!

— Әйдәгез каен суы эчәбез? — диде шул вакыт Мөдәррис.

— Эчик.

— Тик моны соңыннан олыларга лыбырдамаска кирәк.

— Үзем дә беләм.

Бер тапкыр салам кибәнендә уйнавыбызны малайларга сөйләгән идем, ул тишек авызларда сүз торамы соң! Бригадирга кадәр ишеттергәннәр. Шуннан соң бу уенны уйлап чыгарган Мөдәррискә яхшы ук эләкте. Бер атна минем белән уйнамыйча, шуның өчен кинә тотып йөрде. Килә дә якага ябыша — тискәрелек аңарда буа буарлык. Ярар, әйтмәбез соң, гел аның белән бәйләнешүдән ни файда?

Әнә ул бер юан каенның кабыгын ярып маташа. Кабыгын гына түгел, агачын да чокый башлады инде. Пәкесен бөтен көченә батыра да кыйгачлатып кисә. Тагын нишләр икән, дип башта Җәмил белән карап тордык. Мөдәррисебез нәни генә чокыр ясады да, шул чокырга каен суы саркып җыела башлау белән, әй суыра, суыра! Аннары:

— Тәмле-е-е, көч кертә торган, сусыннарны баса. Җыел, җыел, там, там! — дип такмаклый да башлады.

Көч кертә! Менә нигә Мөдәррис дәрманлы икән. Ул гел шулай каен суы эчәдер әле. Без дә Җәмил белән янәшәдәге агачларга сырыштык. Чәй салып килгән шешәләребезне бушаттык та каеннарга асып куйдык. Ризык төргән тастымалны телгәләп, тасмаларның бер башын шешәгә тыктык, икенче башын каен ярыгына кыстырдык. Агачтан саркыган су чүпрәк буйлап шешәгә генә тама: челт, челт. Шундый саф, үтә күренмәле, салкынча! Үзеннән әллә нинди баллы бер ят тәм — агач тәме килә. Бик кызык бу дөнья! Шушы карап торырга бик тә чуар балчык катламнары арасыннан шифалы дым күтәрелә икән ләбаса. Каенны кисеп карасаң, күренми дә үзе. Бары кояшта каралган төп кенә балавызлана, яласаң, аннан чын бал тәмен тоячаксың.

Әнә инде шешә тулып та килә. Мөдәррис агачын икенче урыннан ярып ята инде. Элеккесеннән саран тама башлаган икән.

Без бу юлы каен суын эчеп кенә калмадык, аның белән бит-кулларны да юдык, шешәләрне тутырып өйгә дә алып кайттык. Шулай каенлыкта күпме йөргәнбездер, хәтерләмим. Әмма бер көнне тотылдык. Яңа каенга шешә асып ятканда гына, өстебезгә Шакир абзый килеп чыкты. Без яргалаган каеннарга карап торды да, хөкем иткәндәй, башын селкеде:

— Менә кемнәр икән ул каенлыкны корытучы аяклы фетнәләр!

— Үсә ич ул тагын,— диде Мөдәррис.— Әнә яшь үсентеләре төптән дә бәреп чыгып килә инде.

— Чыгар, чыгар,— диде Шакир абзый коры гына.— Безнең авылга каенлык ничә чакрым хәзер, беләсезме?

— Ике,— диде Җәмил.

Шакир абзый шуның белән исбат иткәндәй әйтте:

— Менә, оланкайларым, хәзер читтә генә үсә шул ул. Бер заман авылыбыз, аландагы сыман, яшеллеккә генә күмелеп утырган. Урманда, каеннар арасында. Ә хәзер, күрәсез ич, ялан кырда, сахрада. Сезнең кебек ваемсызлар «үсә ул» дип шулай кырган аны. Болай ачкүзләнеп тунасагыз, бер заман урман бөтенләй үчәр, үзен бер күрергә дә тилмерерсез әле.

— Без бер-ике агачка гына кагылдык ла...

Тик шулай да бу аклану сүзләрен әйтеп кенә Шакир абзыйны тынычландыра, юата алмадык. Шешәләребезне каен төбенә тәгәрәтеп, агачларны бүтән яраламаска сүз бирергә туры килде. Әмма ул бик ышанып бетмәде, ахры, артыбыздан:

— Тукран тәүбәсе булмасын, карагыз аны! — дип кисәтеп калды.

— Беләсезме нәрсә,— диде Җәмил, кайтырга чыккач,— әйдәгез каралты-кура тирәсенә куаклар утыртабыз?

— Шулай иза чигәсе генә калды,— диде калын тиреле Мөдәррис.

— Чыннан да, менә дигән уй ич бу,— дидем мин.— Әгәр авылда каеннар үстерсәк, шелтәләү кая, шул ук Шакир абзый да рәхмәт кенә әйтәчәк безгә. Авылны яңадан куакка күмеп урманга әйләндерсәкме?!

— Быел соң шул инде, терелмәячәк алар,— дип каршы төште Мөдәррис.— Яфрак яра башлаган инде агачлар.

— Бер дә соң түгел. Мин иртәгә урманга көрәк алып киләм, —диде Җәмил дәртләнеп. — Куаклар төпләргә.

— Мин дә!

Иртәгесен без Җәмил белән урманга җыенганда Мөдәррис тә килеп җитте. Кайсы ягы белән торган-

дыр, бүген үзе куак төпләп кайтырга ашкынып тора.

— «Уфалла»ны да алыйк әле, күтәреп кенә читен ул,— ди.

Менә бусы акыл, ичмасам. Көрәкләр, капчыклар, бауларны арбага салдык та юлга чыктык. Урман эченә әллә ни ерак кермәдек. Башта Зирекле чокырыннан кура җиләге төпләдек. Аннары шактый зур агачларга күз аттык.

— Туфрагы белән төплик без аны,— диде Мөдәррис.— Мин менә бу миләшне төбендә үскән сәрдәләре белән алам. Урмандагы кебек, анысы да тамыр җибәрсен әле бакчабызда.

— Сәрдә авылда нигә үсми, Мөдәррис?

— Күләгәне ярата ул,— диде иптәшебез белдекле генә.

— Бу аланда нинди күләгә булсын ди инде?

— Урман ич бу, һавасы да бүтән. Әйдә казы инде син, көне буе батып ятмабыз ич монда!

Җавап таба алмый башласа, гел шулай кырыслана ул Мөдәррис. Ә минем бик исем китә инде. Казый-казый кулларым да кабара башлады. Әллә тамырга туры килдем шунда, керми дә керми көрәгем.

— Мин дә берне төпләдем. Менә кара әле, Мөдәррис, кара инде? Терелерме икән бу миләш? Быел ул чәчәк атармы? Тамыры да күп өзелмәгән, әйеме? — дип тәтелдәде Җәмил.

Мактанчык. Кикеригеңне шиңдерим әле.

— Харап инде, бармак башы хәтле куак төпләгәнсең икән,— дидем мин юри.— Быел, күр дә тор, яфрагы да борынламас әле.

— Монда зур куаклар юк ич. Мөдәррис, әйдә бергә табыйк әле?

— Нәфесеңне тый, өлгерерсең. Миңа тартыш ичмаса, — ди Мөдәррис.

Бераздан алар ешлыккарак кереп киттеләр. Озакламый шул яктан Җәмилнең:

— Әлә-лә-лә, таптым! — дигән тантаналы тавышы ишетелде.

Шунда ук аның сөенүен Мөдәррис бүлде:

— Юк инде, мин аны әнә тегеннә-ән үк күзләп килдем!

— Ялганлама!

— Нәрсә чәрелдисең, актык агач түгел лә ул. Арырак тагын да матуррак миләш куагы үсеп утыра, күрәсеңме?

— Юан, җитмәсә, бер төптән икәү бәреп чыккан. Үзеңә булсын!

— Берсе миңа! — дип, казый башлаган чикләвегемне ташлап, мин дә яннарына йөгердем.

Менә шулай уздырыштан төпли-төпли, арбабызны төрле куаклар белән тутырдык. Кипмәсен, туфрагы коелып бетмәсен өчен, агач тамырларына капчыклар кигездек.

Шулай алып кайттык та утырттык куакларны. Аларның күбесе бик тиз тернәкләнеп, үсеп китте. Әллә вакытын дөрес сайладык, әллә әйбәт тәрбияләдек инде шунда үзләрен. Куралар гына түгел, сәрдәләр дә баш күтәрде!

Яшь миләшләрне, шомыртларны, бүтән агачларны карарга бер көнне Шакир абзыйны да алып килдек. Йөзе яктырып, тавышлары үзгәреп китте аның.

— Менә бу, рәхмәт төшкерләре, лаеклы эш, менә бу — егетлек, — диде ул куанып. — Бер заман күзгә ямь генә бирмәс, җимешләрен дә татытыр әле бу куаклар. Ул җимешләрдән ничәмә төрле шифалы су да ясарга мөмкин булачак!

Чынлап та, без бит киләчәктә агачларны зарарламыйча да төрле-төрле татлы суга тиенәчәкбез. Аннан әле бәлки сезгә дә өлеш чыгар?

ЭЧТӘЛЕК

Дачада 3
Яңа уен 24
Тукран тәүбәсе . . 35
Илдар 48
Шаяру 54
Фотоаппарат . . . 60
Үпкә 69
Кырда 77
Ярыш 84
Саран күрше . . . 91
Кем гаепле . . . 100
Шифалы су . . . 107

КЕЧЕ ЯШЬТӘГЕ МӘКТӘП БАЛАЛАРЫ ӨЧЕН

Айдельдинов Тауфик Рамазанович
(Тауфик Айди)

НОВАЯ ИГРА

Рассказы

(на татарском языке)

Редакторы *Т. Нурмөхәммәтов.* Художнигы *В. Фомин.* Художество редакторы *Ф. Хәсьянова.* Техник редакторы *Ф. Абдрахманова.* Корректоры *Г. Галиева.*

ИБ № 4921

Җыярга тапшырылды 6.05.88. Басарга кул куелды 3.11.88. Форматы 84×108$^{1}/_{32}$. Китап-журнал кәгазе. Литературная гарнитурасы. Кабарынкы басма. Шартлы басма табагы 5,88. Шартлы буяу-оттиск 6,3. Нәшер-хисап табагы 3,88. Тиражы 15 000 экз. Заказ Е-251. Бәясе 15 тиен. Татарстан китап нәшрияты. 420084. Казан, Бауман ур., 19. Татарское книжное издательство. 420084. Казань, ул. Баумана, 19. Татарстан АССР Нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе эшләре дәүләт комитетының Камил Якуб исемендәге полиграфия комбинаты. 420084. Казан, Бауман ур., 19.

15 тиен.